

БАШКАСЫНА ДА РИЗА

Даруларга кытлык ни сәбәпле пәйда булган да кайчанга кадәр дәвам итәчәк?

> 5

ХАТ ЭЗЕННӘН

Актаныш районында яшәүчеләрне чиста су проблемасы борчый

> 6

РӘСИМ НИЗАМОВ:

«Сәхнәнең дәрәҗәсен төшерүдә үзебезнең дә гаеп бар»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 12 (28979) | Җомга | 27 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАЛАМ, БАГА АЛМАМ

ИЛДӘ БӘБИ ТАБУЧЫЛАР САНЫ КИМИ

Эш, машина, фатир, аннан соң гына бала. Шул рәвешле фикер йөртүчеләрнең артуын туучылар саны кимү дә раслый. Мондый хәл инде биш-алты елдан бирле күзәтелә. Узган ел әни булучылар тагын да азрак теркәлгән. Белгечләр, заманасы шундый, дип акланырга тырышса, икенчеләр әни булган өчен генә дә акча түли башларга тәкъдим итә әнә. Нигә бала тапмыйлар? Бу сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

> 7

Ишетми калмагыз

Республикада узган елның гыйнвар – октябрь айларында уртача хезмәт хакы, алдагы елның шушы ук чорындагыга караганда 16,6 процентка үсеп, 50287,7 сум тәшкил иткән. Аның быел да артуы көтелә, чөнки Россия дәрәҗәсендә хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру турында карар кабул ителде чөнки. Быел 1 гыйнвардан аның күләме – 16242 сум. Татарстанда, бюджеттан тыш секторда эшләүчеләр өчен минималь эш хакы, өчьяклы килешү нигезендә, 19565 сум күләмендә билгеләнде.
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, иң күп акча файдалы казылма чыгару тармагында (уртача 78155 сум), мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә (76245 сум) түләнелә. Ә иң аз хезмәт хакы, элеккечә үк, кунакханә хуҗалыгында, җәмәгать туклануы оешмаларында (икесендә дә – 32,5 мең сум), күчемсез милек белән алыш-бирешләрне теркәү өлкәсендә (34,3 мең сум).

Татарстанда барлык муниципаль берәмлекләр чикләре турында мәгълүматлар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына (ЕГРН) кертелгән. Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова әйтүенчә, республика узган елда Илкүләм киңлекләр мәгълүмат системасын (НСПД) булдыру буенча дәүләт программасын гамәлгә ашыруда катнашучы пилот төбәкләрнең берсе булып торган. Шушы эш нәтиҗәсендә муниципаль берәмлекләр чикләре, яр буе сызыклары, су басу зоналары турында мәгълүматларның барысы да, махсус сакланышлы табигый территорияләр турында мәгълүматларның – 96, урман хуҗалыклары турында – 80, Татарстанга чиктәш төбәкләр (Оренбург өлкәсе, Башкортстан һәм Мари Иле) белән чикләр турында мәгълүматларның 37 проценты реестрга кертелгән.

Татарстанда «Ярдәм янәшә!» республика иҗтимагый хәрәкәте, 23 февральгә багышлап, «Солдатка хат» акциясен игълан итте. «Без махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче егетләребезгә даими рәвештә гуманитар йөкләр җибәрәбез. Аларның һәркайсында хатлар да була. Ир-егетләргә йөрәктән чыккан җылы сүзләр бик кирәк», – ди хәрәкәт координаторы Тимур Сафин. Хатларны гуманитар ярдәм кабул итү пунктына алып килү сорала. Бүгенгә Татарстанда 84 шундый нокта эшләп килә. Барысының да адреслары «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте сайтында (ярдәм.рф) «Ничек ярдәм итәргә?» («Как помочь») бүлегендә күрсәтелгән.

Бу көннәрдә Татарстанда җепшек кар, буран, секундына 16 метр тизлектә җил көтелә. Юлларда – көчле бозлавык. Шимбә – 28 гыйнварда – болытлы һава. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –8 градус күрсәтәчәк. Төнлә –11, урыны белән –16 градус. Якшәмбе – 29 гыйнвар көнне – республикада тагын аз гына кар явып үтәчәк. Көндез –5...–10, төнлә –8...–13, урыны белән 17 градуска кадәр суык булачак.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

23 гыйнварда Әлмәттә быелгы 100 нче бала туган. Анастасия һәм Игорь Устиновлар гаиләсендә дөньяга килгән малайга Тимофей дип исем кушканнар. Өйдә аны абыйсы Артем һәм апасы Арина көтә. Моннан тыш, 24 гыйнварда Әлмәт районында өченче игезәкләр туу да теркәлгән. Шатлыклы вакыйга Алевтина һәм Давид Тунян гаиләсендә була. 2023 елның 19 гыйнварында аларның ике кызлары туа. Яңа туган балаларга София һәм Ева исемнәре кушканнар. София белән Еваны өйдә абыйлары Александр көтә.
(«Әлмәт таңнары»)

Бөгелмә

Карабашның «Нефтьче» стадионында «Аударыш» турниры узды. Әлеге бәйге ат өстендә көрәшүдән гыйбарәт. Ул Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында оештырылды һәм бистәнең ат үрчетүче күренекле кешеләре истәлегенә багышланды. Турнирда Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск, Тукай районнарыннан 16 спортчы катнашты. Алар арасында Татарстан чемпионаты җиңүчеләре һәм призерлары да бар. «Аударыш» ярышлары ике авырлык категориясендә – 80 килога кадәрге һәм аннан авырраклар арасында узды. Нәтиҗәдә Лениногорск һәм Әлмәт районнары вәкилләре җиңде.
(«Бөгелмә-информ»)

Түбән Кама

Югары Уратма авылында модульле фельдшер-акушерлык пункты ачылды. Чарада «Татарстанның муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин, Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллин катнашты. Әлеге объект «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысасында төзелгән. «Авыл җирлегендәге фельдшер-акушерлык пунктына кешеләр медицина ярдәме алу өчен генә түгел, ә киңәшкә дә килә. Авыл медпунктында эшләүче фельдшерлар – чын профессионаллар. Заманча ФАП ачу аларга уңайлы эш шартлары тудыру һәм халыкның тормыш сыйфатын яхшырту гына түгел, ә халык үз сәламәтлегенә игътибарлы булсын өчен этәргеч тә», – диде Рамил Муллин. Моннан тыш, быел Түбән Чаллы һәм Колмакчы авылларында да заманча модульле ФАПлар ачылачак.
(e-nkama.ru)

Мамадыш

Шәһәрнең 1 нче номерлы мәктәбе укучылары окоп шәмнәре өчен калай банкалардан һәм картоннан эшләнмәләр әзерли. Мондый шәмнәр салкын чорда солдатларга су кайнату, ризык пешерү өчен кирәк. Мамадышта аларны әле берничә көн элек кенә җитештерә башлаганнар. Башкалар белән берләттән, бу эшкә мәктәп укучылары да кушылган. Окоп шәмнәре ясарга булышудан тыш, алар, йөрәк җылысын кушып, солдатларга хатлар да яза.
(«Нократ»)

БОЛАЙ БУЛГАНЫ ЮК ИДЕ

ТР Дәүләт Советында

Кичә парламентыбыз үзенең кырыгынчы утырышын уздырды. Ул көндезге 12 тулганчы ук тәмамланды, тулыр-тулмас ике сәгать эчендә депутатларыбыз унбиш закон проектын карадылар, аерым чыгышлар ясарга да өлгерделәр. Парламент тарихында болай булганы юк иде әле. Бу утырыш иң кыскаларыннан берсе булып тарихка кереп калачак.

ПО КОНСТИТУЦИИ	100	
ЗА	73	73,0%
ПРОТИВ	9	9,0%
ВОЗДЕРЖАЛИСЬ	1	1,0%

РЕШЕНИЕ ПРИНЯТО

Шуның өстенә көн тәртибендәге мәсьәләләр дә тарихи яктан бик әһәмиятле иде. Мин, беренче чиратта, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» закон проектын күздә тотам. Махсус төзелгән эшче төркем бу проект белән ярты ел шөгыльләнде. Мәсьәләнең үтә дә җитди булуына парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин аеруча басым ясады, закон проектының бик кызу бәхәсләрдә тууын әйтергә дә онытмады. Фикерләр төрле булса да, бер сүзгә килгәннәр үзе.

Ә нәтиҗә болайрак: 7 бүлек 126 маддәдән торган Төп Законның 6 бүлеге һәм 60 маддәсенә үзгәреш кертелгән, 2 яңа маддә өстәлгән, Конституциянең 25 нормасы үз көчен югалткан. Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә буенча комитет рәисе Альберт Хәбибуллин фикеренчә, «башка әһәмиятле иҗтимагый-сәяси конструкцияләр» шикелле, Төп Закон да үзгәрергә мөмкин. Иң әһәмиятлесе – үзгәрешләр үсешкә китерсен. Конституция дә эволюцион үзгәрешләр кичерергә мөмкин булып чыга инде.

Альберт Хәбибуллин кайбер үзгәрешләргә аерым-аерым тукталды. Мәсәлән, Россия Конституциясенең 129 нчы маддәсендә язылганча, субъектларның прокурорлары Федерация Советы белән киңәшеп билгеләнсә, Россия Президенты карары белән вазыйфасыннан азат ителә.

Декабрьдә Татарстанда Президент атамасын үзгәртү турында закон кабул ителеп, анда үзгәртү өчен күчеш чоры билгеләнгән иде. Ягъни республика башлыгын яңача атау яңа сайланган җитәкчегә генә кагылырга тиеш. Әлеге җитди мәсьәлә буенча тагын бер кат сөйләшкәннән-киңәшкәннән соң, күчеш чорыннан баш тартырга булганнар. Бик гади итеп әйткәндә, утырышта кабул ителгән закон проекты закон көченә алуга, без Рөстәм Нургали улы Миңнехановка яңача, башкача дәшәргә тиеш булачакбыз. Урысча ул «Глава (Раис) Республики Татарстан» дип язылган. Татарча «Татарстан Республикасы Рәисе».

Хакимият органнарының кайбер вәкаләтләре дә үзгәрәчәк. Барлык яңалыкларны да әкренләп-әкренләп күңел аша үткәрәселәр алда әле. Ә депутат Ркаил Зәйдулла утырыш барышында ук үз сүзен әйтеп калырга теләде. Дөрес, үзе ук әйтүенчә, аның чыгышы яудан соң йодрык күрсәтү кебек иде. Чөнки Конституциягә тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча чыгышлар булмады. Парламент рәисе, артык сүз сөйләп, мәсьәләне сәясиләштерүгә каршы иде. Депутатлар аның сүзенә колак салды һәм закон проекты күпчелек тарафыннан хупланды. Каршылар бернчә бөртек кенә иде.

Ркаил Зәйдулла фикере күңелләргә барыбер кереп калырга тиеш. Конституциягә үзгәрешләр кертелгәннән соң, илдә алдынгы саналган Татарстан Республикасы гади бер өлкә хәлендә калачак. Сүз бит Татарстанның тулы мөстәкыйльлеге турында түгел, ә чикләнгән суверенлык турында бара.

Без ничә еллар буе федерализм принципларына нигезләнгән хокукый дәүләт төзү, Россияне көчле итү турында хыялланабыз. Ә Ркаил Зәйдулла үзәктә федерализмга каршы кара көчләр утырмыйлы икән, дип тә шикләнә. Анысы да бардыр. Кайберәүләр көчләп ачылган күздә нур булмавын оныталар. Безнең татарны бәргәләп-суккалап тору кирәкми. Без түлы мөстәкыйльлек алып, Россиядән чыгып китәргә җыенмыйбыз. Алай гына да түгел, татар Россия дәүләтчелеген ныгытуга гасырлар буе үз өлешен кертә килә. Бу хакта сүз чыккан саен, мин Россия Президентының: «Куда нам без татар?» – дигәнен искә төшерәм. Владимир Владимирович бу сүзләрне шаяртып кына әйтмәде, билгеле. Рус, Россия тарихында татарның ролен бик яхшы аңлый ул һәм бүген дә безгә таяна, дип уйлыйм.

Ркаил Зәйдулла халык санын алу нәтиҗәләреннән дә канәгать түгел. Соңгы кампаниянe ул төрле милләтләргә кимсетеп карау дип бәяләде. Парламент рәисе аның белән фикердәш иде. Фәрит Хәйрулла улы әйтүенчә, халык санын алу нәтиҗәләре буенча документлар тәмам әзер булгач, аларга җитди анализ ясарга кирәк. Чөнки бу мәсьәлә җәмгыятьтә шактый киеренкелек тудырды. Нәтиҗәләрдән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та канәгать түгел.

«Тәкъдимнәрегезне уйлый торыгыз. Халык санын алу мәсьәләсе безне генә түгел, Россия төбәкләрендә яшәүче башка халыкларны да борчый», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

НАЧАР БЕТӘЧӘК...

Татарстан Президенты, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Төркем әгъзалары исеменнән Швеция һәм Нидерландның Россиядәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчеләренә, әлеге илләрдә Коръәнгә карата кылынган вәхшилек гамәлләрен гаепләп, хатлар юллады.

«2023 елның 21 гыйнварында – Стокгольм шәһәрендә һәм 2023 елның 23 гыйнварында – Гаага шәһәрендә Коръәнне мәсхәрәләп, коточкыч вәхшилек гамәлләре кылынды. Россиядә – ә ул дөньяның ислам цивилизациясе тарихына Коръән бастыру үзәкләреннән берсе буларак кереп калган – бу гамәлләр мөселманнары гына түгел, башка дин вәкилләрен дә шок хәлендә калдырды. Илебез дөньядагы традицион диннәрнең гореф-гадәтләрен кадерләп саклап килгән бер мәлдә, мәгърифәтле дип саналучы Европа үзәгендә Изге Китапны, бөтен кешелеккә иңдерелүен онытып, ачыктан-ачык мыскыл итәләр.

Цивилизацияле дөньяда күршеләрнең дини хисләре, аларның мәдәни традицияләре һәм диннәре хөрмәт ителергә тиеш. Теләсә кайсы нормаль җәмгыятьнең төп кыйммәте шуннан гыйбарәт.

Читләрнең рухи кыйммәтләрен һәм әхлакый нигезләрен аяк астына салып таптауга юл куйган сүз һәм гамәл ирегe теләсә кайсы җәмгыятьне җимерердәй җитди куркыныч булып тора. Динне мәсхәрәләүгә юл куйган цивилизацияне, иртәме-соңмы, әхлакый яктан таркалу һәм җимерелү көтә. Кызганычка, Швеция һәм Нидерландтагы әлеге вакыйгалар дин тотучыларның хисләрен кимсетүнең дәвамына гына әйләнде.

Әлеге коточкыч гамәлләрне хакимияттәгеләрнең дәшми генә хуплавы, хокук саклау органнарының битарафлыгы чиктән тыш зур борчу тудыра.

Изге китапларны мәсхәрәләүне берничек тә аклап булмый. Бөтен дөнья мөселманнарын мыскыллау, диннән көлү, демократия һәм гомумкешелек кыйммәтләре белән бернинди дә уртаклыгы булмаган ксенофобия акты бу.

Без – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме әгъзалары, бөтен дөньядагы миллионнарча мөселман белән бергә телгә алып үтелгән мыскыллау гамәлләрен гаеплибез һәм мондый коткыларга, һичшиксез, юл куелмаска тиеш, дип саныйбыз», – диелгән хатларда.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

Нәтиҗә

Авыллар интернетлы, шәһәрләр камералы, хезмәтләр онлайн. Цифрлаштыру елы уңаеннан башкарылган эшләрнең бер өлеше генә әле бу. Ел уңышларын тармак министрлыгы Татарстан Президенты белән бергә барлады.

tatarstan.ru

АЧЫК КАПКА

Узган ел күп тармаклар өчен сынау елы булды. Цифрлаштыру өлкәсе дә искәрмә түгел. Шуңа күрәме икән, Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин коллегия утырышында мактану юлын сайламады. Алдан ук проблемаларга игътибар итәсен әйтте.

Шулай да башкарган эшләрне игътибарсыз калдырып булмый бит. Газ, су, ут кебек үк мөһим һәм кирәк булган интернетка тоташтыру юнәлешен генә алыйк. 2022 елда югары тизлекле интернетка тоташтырылган хуҗалыклар 24 мең абонентка арткан. Бу юнәлештә Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Татарстан беренчелеккә чыккан. Шулай итеп, республикада чыбыклы интернетка хуҗалыкларның 79 проценты ия. Бер ел эчендә 132 торак пункт интернетлы булган. 2023 елда да бу программаны гамәлгә ашыруны дәвам иттерәчәкләр. Хыял – 400ләп торак пунктны колачлау.

Тик менә трассалардагы интернет мәсьәләсе кала бирә. Министр әйтүенчә, елдан-ел интернет тотмаган «ак тап»лар кимесә дә, бетеп җитмәгән әле. Яңа юллар да төзелә, аларда исә барысын да яңадан булдырырга кирәк. Тик ул бер урында берничә операторны урнаштыру яклы түгел. Бу һәрвакыт мөмкин дә түгел әле. Әлеге сорау белән федераль дәрәҗәгә чыгарга кирәк, дигән фикер әйтелде коллегиядә.

Видеокамералар да артачак. Айрат Хәйруллин әйтүенчә, видеокүзәтү һәм видеоаналитика буенча бердәм хезмәт министрлык һәм хокук саклау структуралары белән берлектә барлыкка килергә тиеш. Республика территориясендә 99 мең видеокамера урнаштырылган икән инде. Шуларның 5 меңнән күбрәге – кеше күп йөри торган урыннарда, 40 мең тирәсе – күпфатирлы йортларда. 2023 елда исә 1127 видеокамера урнаштырырга ниятләнә. Бу «Имин шәһәр» проекты кысасында башкарылачак.

Тагын бер борчыган мәсьәлә – үзебезнең кадрлар һәм импортка алмаш табу. 2022 ел моны тизләтте дә, моннан качып котылып булмаячагын да искәртте. Министр әйтүенчә, чит ил программаларының 80 процентына Россиядә җитештерелгән алмаш бар инде. Шулай ук IT компания һәм «акыллы баш»лар өчен эш җитәрлек.

«Акыллы баш» димәктән, IT белгечләргә кытлык бар инде ул. Министр сүзләренчә, Татарстанда ел саен 10 меңләп шундый белгечкә ихтыяҗ бар. Аны капларлык кадрлар юк: 2022 елда 4,4 мең кеше шушы белгечлек буенча дипломлы булган.

Ел киеренке булса да, Татарстанда IT компанияләр саны ишәйгән. Узган ел 95 яңа компания өстәлгән. Хәзер аларның саны – 3 мең. Былтыр Татарстанның 46 компаниясе 740 млн сум күләмдә акчалата ярдәм алган.

Цифрлаштыру елы игълан ителгәч, иң мөһим максат итеп, халыкның тормыш сыйфатын күтәрүне атаганнар иде. Моңа хезмәтләрне өйдән чыкмый гына, ягъни онлайн алу мөмкинлеге дә керә. Татарстанда республика һәм муниципаль хезмәтләрнең 100 проценты электрон рәвешкә күчерелгән. 2020 елда онлайн рәвештә нибары 27 хезмәттән файдаланып булган, бүген аларның саны – 319.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, былтыр башкарасы эшләргә вакыт та, мөмкинлекләр дә күп сарыф ителгән. Юкка булмаган анысы. Ә алда тагын да күбрәк эш көтә. Монысын Президент та әйтә. Хезмәтләрне цифрлаштыру, башка мәсьәләләр дисеңме. «Кайбер проектларның саннары зур, әмма эчтәлек тирәнлеге… Күбрәк эшләргә кирәк булыр. Хәзер иң мөһиме – «Имин шәһәр» проекты. Эчке эшләр министрлыгы чыгарган нәтиҗәләрдән шуны күрергә мөмкин: уңай вазгыятькә, нигездә, санлы системалар җәлеп итү бәрабәренә ирешелде. Әйтик, камералар кую, «акыллы домофон» урнаштыру. Алга таба да бу эшне дәвам иттерергә кирәк. Бу мөһим», – диде ул.

Әлбәттә, тармак хәле җиңел түгел. Моңа ил-көндәге вазгыять тә йогынты ясый. Республика ярдәме дә, федераль ярдәм дә кирәк. «Бер яктан караганда, авыр, икенче яктан карасак, безнең өчен бөтен мөмкинлекләр ачык», – диде Президент.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«ВТ» бүләкләре Кукмара, Зәй һәм Сабага китә

Сез дә көткәнсездер, без дә бик көттек. Абунәчеләребезгә дип әзерләгән бүләкләребезнең ияләре билгеле булды. Уенда катнашырга теләк белдереп, 43 районнан 986 укучыбыз үзләренең квитанцияләрен җибәрде.

Билгеле булганча, квитанцияләрне электрон почта, «Ватсап» һәм почта аша конвертларда кабул иттек. Һәркайсын теркәп, номер сугып, әрҗәгә сала бардык. Бүләк отучылар гадел итеп, жирәбә юлы белән билгеләнде.

МЕНӘ БЕЗНЕҢ БҮЛӘК ИЯЛӘРЕ:
мультиварка – Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан **Гөлнара Хәсәнова**;
микродулкынлы мич – Зәй шәһәреннән **Рәмзия Хәбибуллина**;
суыткыч – Саба районының Зур Кибәче авылыннан **Әнисә Гатиятова**.

Бүләк отучыларның **89179270040; 8 (843) 222 09 65** номерларына редакциягә шалтыратуларын сорыйбыз.

БИЗНЕС ТӘГӘРМӘЧЕ

Икътисадта хәлләр шәптән булмаса да, узган ел Татарстанда эшмәкәрләр саны 3 процентка арткан. Ә 1 гыйнварга булган мәгълүматлар буенча, кече һәм урта эшмәкәрлектә мәшгуль булучылар саны гомуми икътисадтагыларның 39,2 процентын алып тора.

Журналистлар белән очрашу вакытында Татарстан икътисад министры урынбасары Айрат Шәмсиев әнә шулай дип белдерде.

Билгеле булганча, Татарстанда 2020 елдан бирле эшмәкәрләргә ярдәм итүче илкүләм проектлар тормышка ашырыла. Проектларның берсе – үзмәшгульләргә, икенчесе – яңа гына эш башлаучыларга, ә өченчесе эшләп килүче кече һәм урта бизнес вәкилләренә ярдәмне күз уңында тота. Әйтик, 25 яшькә кадәрге яшь эшмәкәрләргә 100–500 мең сум күләмендә ярдәм күрсәтелгән. Үзмәшгульләргә дә ташламалы микрозаемнар һәм поручительләр тәкъдим ителгән.

Айрат Шәмсиев әйтүенчә, гомумән алганда, Татарстан бизнесына узган ел 6,4 млрд сум акча бирелгән. 12,5 мең эшмәкәрлек субъекты республика ярдәме алуга ирешкән. Әлеге чаралар кече һәм урта бизнеста җитештерүчәнлекне җәелдерергә, эш урыннарын саклап калырга һәм яңаларын булдырырга ярдәм иткән. Моннан тыш, республикада федераль ярдәм программаларына җәлеп итүгә дә зур урын бирелә. Шулай итеп, узган ел федераль чаралар кысасында Татарстан бизнесы 80,8 млрд сумнан артыграк ярдәм алуга ирешкән.

Узган ел сәнәгать паркларына да зур игътибар бирелгән. Бүген Татарстанның барлык сәнәгать паркларында 1562 резидент бар. Аларда 52 меңнән артык кеше эшли.

– Яңа инвестицион проектлар барлыкка килде, һәм нәтиҗәдә узган ел башыннан резидентларның гомуми саны – 35 оешмага, ә хезмәткәрләр саны 10 мең кешегә артты, – диде Айрат Шәмсиев.

Узган ел инженер һәм юл инфраструктурасы өчен Арча, Алексеевск, Минзәлә, Түбән Кама сәнәгать паркларына акча бүлеп бирелгән. Быел да әлеге программа игътибардан читтә калмаячак. Аның өчен 500 млн сум акча бүлеп биреләчәк.

Татарстанның Гарантия фонды директоры Рөстәм Мөхәммәтшин әйтүенчә, соңгы елларда кредит алу мәсьәләсендә уңай үзгәрешләр күзәтелсә дә, заем алганда авырлыклар да бар. Әйтик, банклардагы югары ставка, залог суммасы җитмәү, залогка куела торган милекне бәяләгән дисконт, кредит алгандагы чыгымнар.

– Гарантия фонды эшмәкәр һәм банк арасында килеп чыккан авырлыкларны хәл итәргә булыша. Без поручитель буларак ярдәмебезне тәкъдим итә алабыз. Узган ел поручительлек бирү 65 процентка артты, – диде ул.

Әйтеп кенә бактым

Шәүкәт әзи

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бажайның кызы Лилия бала тапкач, аңа Шәүкәт дип исем куштылар. Бүгенге заман өчен бу исем көтелмәгәнрәк, «мода»дан артта калган кебек тоелды. Үзем ят итмәдем бу исемне, чөнки тормыш юлымда Шәүкәтләр күп очрады, барысы да яхшы кешеләр иде. Заманында шактый ук дәрәҗәдә якыннан аралашкан шагыйребез Шәүкәт ага Галиев үзе генә дә ни тора! Хатынның җизнәсе дә Шәүкәт исемле иде. Аңа Елховай халкы гел «әзи» дип эндәште. Бирелә «әзи» дип бик хөрмәтле кешегә эндәшәләр һәм мондый хөрмәт Риман абзагызга да тәтеде.

Кыскасы, Лилиянең баласын да «әзи» дип йөртә башладым. Шәүкәт әзигә хәзер биш яшь, мин «әзи» дигәч, әй, елмаеп җибәргән була сабый. Акыллы, төпле, мөстәкыйль егет үсеп килә бу нәселдә. Артык берни сорамас, көйсезләнмәс, әтисе Илнар нидер эшли башласа, янына барып, шундук булыша башлар Шәүкәт әзи. Әти-әнисе беркайчан да: «Кит әле, бар, аяк астында чуалма», – димәс. Киресенчә: «Ай, улым, маладис!» – дип кенә торырлар. Бик тиз кул астына керде Шәүкәт әзи, әтисенә ияреп, хәтта репетицияләргә дә йөри. Илнар заводта эшли һәм шул ук вакытта төрле тамашалар, юбилейлар да алып бара. Ә тамада җырлый да, бии дә белергә тиеш бит инде, шуңа күрә талантын чарлар өчен репетицияләргә йөри һәм әзине дә үзе белән ала.

Яңа гына бер шатлыклы хәбәр ишеттем. Лилиябез икенче балага йөкле икән. Беркөнне хатын-кызлар консультациясенә барганнар болар. Балаларның бар соравы «Нигә?», «Ни өчен?» бит инде. Шәүкәт әзи дә: «Ә нигә барабыз анда?» – дигән. Лилия: «Синең сеңелкәшне карарга», – ди икән.

Барганнар болар. Лилия табибка кереп чыккан. Ә Шәүкәт: «Ә минем сеңелкәш кайда, ник бирмәделәр?» – дип сораган да елап җибәргән. Лилия ничек дип җавап бирергә дә аптыраган. Биш яшьлек балага: «Синең сеңелкәш әле минем карында гына, аны УЗИ аша гына күрсәттеләр», – дип әйтә алмый бит инде. Әйтсә дә, Шәүкәт әзи берни дә аңламаячак. «Соңрак алып кайтырбыз, аны табиб бүген бирмәде әле», – дигән булган үзе. Ә Шәүкәт: «Соңрак кайчан була инде ул? Табибтан үзем сорап карыйм әле, әни, может миңа бирерләр», – дип тарткалаша башлаган. Юл буе күз яшьләре белән елап кайткан сабый. «Сеңелкәшне кайчан алып кайтабыз?» – дип, әти-әнисен көн саен интерәтә икән. Белмим инде, бу бала көйсезләнүе генәме, әллә башка нәрсәме? Элек балалар авызыннан: «Миңа энекәш кирәк, сеңелкәш кирәк!» – дигән сүзләр чыкмый иде кебек. Чөнки сугыштан соңгы авыр елларда да ишле гаиләләр шактый иде. Элек өч балалы гаилә кечкенә кебек кабул ителсә, хәзер андыйлар турында гаҗәпләнеп сөйлибез. Демографик вазгыять өчен борчылабыз. Шәүкәт әзи, әлбәттә инде, болар турында уйлый белми, әмма үзенә иптәш кирәклеген күңеле белән сизенә кебек.

Гаилә кору, өй тутырып балалар үстерү, бәлки, безгә генләр аша килә торган язылмаган бер кагыйдә, закондыр. Элек «бала кирәкме, ничә кирәк?» кебек уйлар берәүнең дә башына кереп карамагандыр. Хатыннар йөккә узган да тапкан. Элек корсак төшерү дигәннәре дә юк иде кебек. Бәлки, медицина ягыннан караганда аның мөмкинлеге дә булмагандыр. Әмма мин, мәсәлән, авыл кешеләренең корсак төшерүне зур гөнаһка, хәтта җан кыюга санап сөйләгәннәрен хәтерлим әле. Фәлән авылда фәлән хатынның корсак төшерүе җинаять саналды.

Бүген халык саны кимү, халык санын алу нәтиҗәләре турында сүзләр куерды. Күп кенә халыклар, шул исәптән без – татарлар да кимегәнбез икән бит! Моңа ышанасы да килми. Күп кенә танышларыма шалтыратып чыктым, халык саны алучыларны күрмәдек, диләр. Булган кешене «юк» дип язу да җан кыю түгел микән, дип тә уйлап куям. Бит илдә күпме халык, ничә милләт яшәвенә карап, идеология барлыкка килә, дәүләт сәясәте алып барыла. Ирексездән, Шәүкәт әзи кебек: «Сеңелкәшем кайда?» – дип кычкырасым килеп китә.

Лилия аңа сеңелкәш, энекәшләр тапсын, гаиләләре ишле булсын, бер-берсе белән җитәкләшеп үссеннәр. Гаилә, классик әйтмешли, җәмгыятьнең күзәнәге. Ә мин үземнән: «Гаилә – милләтнең киләчәге», – дип тә өстәр идем.

Башыма шундый уйлар керткән өчен Шәүкәт әзигә рәхмәт!

КИРЕ СҮЗ ИРЕГЕ

Стокгольмда Даниянең Stram Kurs (Катгый курс) ультрауң партиясе лидеры Расмус Палуданның Коръән яндыру акциясе бөтен дөньяда зур яңгыраш тапты, гаугa чыгарды. Сәяси момент шундый иде: Швеция НАТОга керергә тели, әмма аның бу омтылышына Төркия аяк чала. Юк, Әнкарада шведларның Төньяк Атлантик альянска керүенә принципиаль каршы түгелләр үзе, әмма шарт куялар: көрд террорчыларын яклауны туктатырга, илдә качып яшәүче экстремистларны Әнкарага тапшырырга. Шведлар бу таләпне үтәргә бик ашыкмадылар, үз законнарының моңа каршы булуын әйтеп акландылар, ләкин Әрдоган каты торды. Акрынлап булса да төрекләрнең таләбен тормышка ашырмыйча мөмкин түгел иде.

Төркиянең НАТОда тоткан урыны бераз үзенчәлеклерәк. Нигездә Көнбатышның либераль идеологиясен тоткан дәүләтләрдән торган блокта күпләп мөселманнар яши торган илгә бераз читрәк итеп карау яши. Хакимияттә Әрдоган торган елларда төрек җәмгыятендә тектоник үзгәрешләр старт алды: мөселманнарның кайчандыр юкка чыгарылган хокуклары торгызыла башлады. Төрек хатыннары яулыктан йөрү хокукын кайтардылар, ислам мәчет стеналарыннан урамга да чыга башлады. 2016 елгы хәрби түнтәрелеш уңышсызлыкка очраганнан соң, төрек секуляристлары, ягъни диннең дәүләттән аерылуын куәтләүчеләр көрәшнең ачыктан-ачык ысулларын куллану мөмкинлеген югалтты. Әмма көрәш һаман да дәвам итә.

Соңгы елларда Төркиядә технологик алгарыш көчәя, хәрби куәте арта һәм ул күп кенә төбәкләрдә үз ихтыярын тагучы державаларның берсенә әйләнеп килә. Төрек армиясе зурлыгы буенча НАТОдагы икенче армия булып санала, аның белән исәпләшми мөмкин түгел. Соңгы көннәрдә генә Америка басмасы «The Hill», «Төрек дилеммасы һәм АКШ куәтенең чикләре» дигән аналитик язма бастырып, Вашингтонга Төркия белән мөнәсәбәтләрне ныгытырга кирәк дигән сөземтә чыгарды. Төрек – швед каршылыгының Әнкара файдасына хәл ителүгә таба баруын Көнбатышта исламның җиңү адымы буларак кабул итүче көчләр байтак. Шулар ачыргаланулы адымга бардылар: швед хөкүмәтеннән төрек илчелеге каршында Коръән яндыру акциясенә рөхсәт алдылар. Рәсми Стокгольм акланды: без үз адымны яклалмыйбыз, әмма нишләтәсең, сүз ирегe, диделәр. Әнкара бу уңайдан бик табигый реакция белдерде: Швециянең оборона министры Төркиягә визит белән килергә тиеш иде – әзерлек туктатылды, илнең НАТОга керү шансы нульгә якынлашты. Әрдоган: «Исламга каршы акцияләрне хуплаганнан соң, шведларга безнең аларның НАТОга керүләренә ризалыгыбызны көтәргә кирәкми. Алар үзләрен исламның дошманнары һәм террорчылар буларак күрсәттеләр», – диде. Хәзер көнбатышлылар быел җәйге сайлауда Әрдоган җиңелер дә вазгыять үзгәрер дип көтәләр.

Рәсми Стокгольмның үз-үзен тотышы бик табигый рәвештә мөселман дөньясында нәфрәт уятты. Төркиянең көрдләр яшәгән провинциясендә, мәсәлән, меңләгән кеше катнашында протест акциясе оештырылды. Коммунистик карашлы көрд Эшчеләр партиясе террорчылары белән көрд халкының бер үк нәрсә түгеллеген раслый ул акция. Швед хөкүмәтенең, университетларының һәм банкларының сайтлары ватылды, аларда Кәгъбә фонында азан яңгырады. Мөселман лидерларының, мөфтиләрнең күпсанлы белдерүләре дә игълан ителде. Стокгольм акциясен Нидерланд экстремистлары да элеп алды. Эдвин Вагенсвельд атлы радикал Гаагада Коръән яндырды.

Вакыйганың кыскача алтарихы шундыйрак. Бу көрәш – имансызларның Коръәнгә һөҗүмнәре Мәккәдә Мөхәммәдкә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Аллаһның сүзләре иңдерелә башлаганнан бирле бара инде. Гасырлар буе барган дискуссиядә имансызлар гел оттыра һәм төрле астыртын адымнар ясарга мәҗбүр булалар: мөселманнарны үтерәләр, хурлыйлар, яла ягалар… Без бүген дә шул көрәшнең заманга яраклаштырылган алымнарын күзәтәбез. Коръәнне яндыру Аллаһның китабына бер зыян да салмый, чөнки барлык экземплярларын яндырып бетерсәң дә, Китап миллионлаган хафизларның күңелендә яши. Ә радикалларның Стокгольмда һәм Гаагадагы кыланышлары – көчсезлек һәм ачыргалану билгесе генә ул. Алар инстинктив рәвештә тоялар: киләчәк – мөселманнарныкы. Ялган икътисадый система һәм ялган либераль идеология үз тарафдарларын һәлакәткә алып бара: демографик кризис һәм финанс кризисы кире кайтарып булмаслык дәрәҗәдә үзләренең финиш сызыгына хәрәкәт итәләр. Мең Stram Kurs оештырсаң да, алардан котылып булмый.

Исламның дошманнарына аны җиңү өчен Китап яндырып мәшәкатьләнергә кирәкми. Аллаһы Тәгалә аларга Китапта беренче карашка бик җиңел булып тоелган бурыч куя: «Коръәнгә охшаган китап языгыз», – ди. Соңрак бер сүрә булса да язып күрсәтергә тәкъдим итә. Әйе, көрәшнең иң нәтиҗәле ысулы шул була алыр иде бит инде, бер генә булса да Коръәнгә охшаган китап яза алсаң да, син исбатлыйсың: андый китапны таланты булган һәркем яза ала. Яндыруга, хурлауга ихтыяҗ бетә. Моннан берничә ел элек бу юлларның авторы: «Ни өчен имансызлар Коръәнгә охшаган китап яза алмыйлар?» дигән татарча һәм русча язмалар язып, интернетка элгән иде. Атеизм тарафдарлары ул язманы бик авыр кабул итте, авторга «террорчы» ярлыгын бик тиләп тактылар. «Яхшы, шулай булсын, әйдәгез, сез Коръәнгә охшаган бер сүрә язып, минем дәлилне кире кагыгыз», – дигән тәкъдимне кабатладым. «Без язар идек, аннан соң сез безне үтерәчәксез», – дигән сәер гаеплəүләргә кадәр барып җиттеләр. «Коръәндә кушканны үтәгән өчен бер мөселман да сезне үтермәячәк, ә менә үти алсагыз, безне җиңәчәксез», – дидем аларга.

Эш шунда: Аллаһы Тәгалә имансызларга алар берничек тә үти алмаячак бурыч куя: Коръәннең яңгырашын, стилен кабатларга куша. Тукай шигыре кебек яңгыраган шигырьне язу кыен түгел, Пушкинныкына охшатып та шигырь язып була. Андый эшләр белән гадәттә таланты сай булган графоманнар шөгыльләнә, кайсы да булса бер зур авторга ияреп, шуңа охшатып язалар. Коръән иңгән чорда гарәпләрдә шигърият бик үскән була. Ел саен шигърият конкурслары уздырыла, күпсанлы шагыйрьләр катнаша, җиңүчеләр билгеләнә. Шуңа күрә алар үз алларына куйган бурычны яхшы аңлыйлар: тырышып карыйлар, берни дә барып чыкмый. Шуннан берише Китапны кеше яза алмавын аңлап, иман китерәләр, калганнары: «Ул – сихер», – дигән позиция сайлый. Хәтта пәйгамбәр белән бәхәс алып бару өчен, сихерне һәм шигърияттне яхшы белгән Гутба ибн Рабига дигән кешене җибәрәләр. Аллаһның илчесе янынан ул фикерен үзгәртеп кайта: «Аллаһ белән ант итәм, аның сүзләре шигырь дә түгел, сихер дә түгел, күрәзә дә түгел. Әй, корәешләр, мине тыңлагыз, ул кешегә, ни теләсә, шуны эшләргә ирек бирегез, аңа кагылмагыз. Аллаһ белән ант итәм, аның мин ишеткән сүзләрендә бөек хәбәр бар!» – ди. Аңа инде Мөхәммәднең (салләллаһу галәйһи вә сәлләм), чынлап та, Аллаһ илчесе, Коръәннең Аллаһ китабы икәне аңлашыла башлый, әмма ул барыбер кәфер булып кала. Менә бу бурычны – Коръән стилендәге китап иҗат итү бурычын гасырлар дәвамында беркемнең дә үти алганы юк әле.

Ислам тарихында мөселманнарның бөек җиңүле еллары да, түбәнлеккә төшеп, тар-мар ителгән гасырлары да бар. Җиңелү ачысын мөселманнар Коръәннән ерагаеп, аның белән гамәл кылудан туктаган чакта татыйлар. «Ий, мөэминнәр, Аллаһудан каты куркыгыз, Аның хөкемнәрен боздан бик сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселманнар хәлендә генә үлегез», – дигән Аллаһ әмере («Гыймран» сүрәсе, 102 нче аять тәфсире) үтәлми башлау белән, мөселман дөньясы түбәнлеккә төшә һәм дөньядагы лидерлык ролен югалта. Әмма күтәрелеш башлана ул барыбер. Без менә шул яңарыш чорының бусагасында яшибез. Бу юлларны язучы кайчандыр мөселманнардан тартып алынып, бер бүлмәсе «Ленин бүлмәсе» дип атала башлаган мәчеттә башын сәҗдәгә ора. Ленинизм ташланды чүплеккә, ислам исә көннән-көн күтәрелә. Әле кайчан гына халык газеталарда: «Мәчет ишекләре йозакта», – дип уфтанып яза иде, авылларның күбесендә биш вакыт намаз укыла, уфтанырга сәбәп бетте. Европада да күзәтелә бу хәл: элекке чиркәүләр мәчеткә әверелә. Stram Kurs һәм аның лидеры – ачырганануның бер мисалы гына ул. Соңгы еллар Европасында радикал исламофобларның исламны кабул итү очраклары да билгеле. Аллаһ, теләсә, калебләрне үзгәртә. Расмус Палудан кебекләргә мөселманнарның иң яхшы җавабы – Коръән белән гамәл кылуга күчеп, ислам әхлагын тормышка ашыру, изгелек юлына басу. Менә шул чакта Аллаһның вәгъдәсе тормышка ашачак: «Иман китереп, изге гамәлләр кылган хак мөселманнарны Аллаһ Җир йөзендә хуҗа итәргә вәгъдә кылды болардан әүвәлге мөселманнарны хуҗа иткән кебек… («Нур» сүрәсе, 55 нче аять тәфсире). Бу вәгъдә – ислам юлындагыларның лидерлыгы – мөселманнар шартын үтәү белән үтәләчәк һәм ул көн якында.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТАНСЫК ТӨЙМӘ

ДАРУГА КЫТЛЫК СӘБӘБЕ НИДӘ?

unsplash.com

Шәм яндырып эзләсәң дә юк! Чиренә каршы дару таба алмыйча интегүчеләр бүген шулай дип көрсенә. Бу көннәрдә республика даруханәләрендә кабат кайбер даруларга кытлык пәйда булган. Берәүләр тамак авыртканда файдаланыла торган, температура төшерә торган дару булмаудан зарланса, икенчеләре яман шешкә каршы кулланылучы препарат таба алмый интегә. Даруларга кытлык ни сәбәпле пәйда булган да кайчанга кадәр дәвам итәчәк? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга ачыклык кертергә тырышты.

Башкасына да риза

Ун елдан артык күкрәк яман шешенә каршы көрәшүче Казанда яшәүче Гөлфия Харисова бу көннәрдә тынычлыгын югалткан. Катлаулы операциядән соң даими рәвештә эчеп торган «Тамоксифен Гексал» исемле даруы даруханәләрдән юкка чыккан.

– Шуны эчеп, гомеремне ничә елга озайткан идем бит. Бу көннәрдә шул даруны таба алмый тилмерәм. Казанда гына түгел, Мәскәүдәге даруханәләрдә дә калмаган ул. Хәтта Якутиядән дә эзләттек. Анда да юк. Төркиядә генә бар. Әмма аннан кайтарту кыйммәткә төшә. 200 сумлык даруны кайтарту 1000 сумга чыга, – ди Гөлфия ханым.

Арчада яшәүче өч бала анасы Алсу Шәрипова да гыйнвар башыннан бирле «Амоксиклав» дигән антибиотик таба алмый икән.

– Яңа ел ялларында тамакка үлекле ангина чыкты. Аны антибиотиксыз җиңеп булмый бит. Каты авырганда гел «Амоксиклав»ның файдасын күрә идем. Хәзер ул даруханәләрдә сатылмый башлаган. Районнан гына түгел, Казандагы бөтен даруханәләрдән дә эзләттек. Юк, диләр. Кайчан кайтачагын да белмиләр. Яңа ел алдыннан «Амоксиклав»ның сироп рәвешендәгесен – балалар өчен чыгарылганын эзләп хәлдән тайган идек. Хәзер үзеңә килешкән даруларны, авырмасаң да, алдан запаска алып куярга икән, – ди Алсу.

Кызыксына торгач, әңгәмәдәшләребез кебек кыен хәлгә калучылар күп булып чыкты. Соңгы арада даруханәләрдә, алда телгә алган дарулардан тыш, балаларның температурасын төшерүче «Нурофен»га да кытлык.

– «Нурофен»ны көн саен диярлек сорап керәләр. Телефон номерларын калдыралар, дару кайтуга ук шалтыратып әйтүебезне үтенәләр. Бу даруларның аналогларын тәкъдим итеп карыйбыз. Әмма ата-аналарның күбесе: «Ул дарулар безгә килешми», – дип баш тарта. Элегрәк гел сатылып килгән «Амоксиклав», «Аугментин», «Цефуроксим» кебек дарулар бездә күптән юк инде. Кайчан кайтачагы да билгесез, – дип җавап бирделәр безгә башкаладагы даруханәләрнең берсендә.

Безнең редакция янындагы даруханәдә дә бүген, нигездә, антибиотикларга кытлык икән. «Дару бер җирдә булмаса, икенчесендә дә беткән була инде ул. Шуңа хәзер кеше даруларның аналогларына да каршы килми. Кулга тотып килгән рецептында ук табиб бер дару исеме янына 3–4 аналогының исемен дә күрсәткән була», – диде биредә эшләүче фармацевт кыз.

Озак көттермәс, диләр

Әле Яңа ел алдыннан гына даруханәләрдән, ду китереп, вируслы сулыш юллары авыруы вакытында ингаляция ясау өчен кулланылган «Пульмикорт» даруын эзләгән идек. Бу юлларны язганда, аның даруханәләргә җитәрлек күләмдә кайтарылганлыгы ачыкланды. Белгечләр, калган дарулар да озак көттермәс, ди.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, алда телгә алган «Амоксиклав» антибиотигы республика даруханәләренә беренче квартал азагына кадәр кайтачак. Хәтерләсәгез, узган елның көзендә бу даруга бер зур кытлык булып алган иде инде. Ул чакта моны илдә мобилизация башлану, логистикадагы тоткарлыкларга бәйләп аңлаттылар.

Тоткарлык димәктән, ата-аналар дөнья бетереп эзләгән балалар «Нурофен»ының даруханә киштәләрендә кайчан пәйда булачагы билгесез. Һәрхәлдә, «ВТ» хәбәрчесенә министрлыкта бу уңайдан төгәл генә җавап бирә алмадылар. «Бүген даруханәләрдә балалар өчен составы «Нурофен»ныкы белән бер булган, температураны төшерүче «Ибупрофен», «Ибупрофен-Акос», «Ибупрофен-акрихин» исемле дарулар җитәрлек санда бар. Шул ук «Нурофен»ның зурлар өчен чыгарылганына да кытлык юк», – дип белдерделәр безгә министрлыкта.

11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова да ата-аналарга булмаган даруны эзләп вакыт уздырмаска, аларның аналогларын алырга киңәш итә.

– Узган ел азагында халык, бигрәк тә балалар бик нык авырып алды. Даруханәләрдә кайбер даруларга кытлык, нигездә, әнә шул сәбәпле пәйда булды. Әмма бу уңайдан чаң сугарга кирәкми. Даруларның үзебездә җитештерелгән аналоглары бар бит. Аларга шикләнеп карамасыннар. Аналог дарулар да шундый ук көчкә ия, алар да шундый ук нәтиҗә бирә, – ди табиб.

Гыйнварның беренче яртысында даруханәләрдә яман шешкә каршы «Тамоксифен» даруы да сатылган. «Әмма ихтыяҗ зур булу аркасында, ул бик тиз сатылып бетте. Бу препарат республика даруханәләренә февраль аенда кайтыр, дип көтәбез. Ә менә «Тамоксифен Гексал» дигән дару исә Россиядә башка сатылмаячак», – дип белдерделәр безгә министрлыкта.

Вакытында кайта

Росздравнадзор идарәсендә кайбер даруларга кытлык пәйда булу сәбәбе дип аларга ихтыяҗ зур булу һәм бу препаратларны кайтартканда килеп чыккан юл мәшәкатьләрен күрсәтәләр.

– Дистрибьюторлар логистикага бәйле кыенлыкларны хәл итеп, даруларны вакытында кайтарып җиткерү юлларын эзли. Даруларга кытлык булган чорда мошенниклар да активлаша. Фәлән даруны табып, тиз арада кайтарып бирү өчен акчаны алдан түләп куюны сорый алар. Аннары алыпсатар кулыннан алган дару ялган яки сыйфатсыз да булырга мөмкин бит. Шуңа күрә бу очракта кеше акчасын гына түгел, сәламәтлеген дә югалтырга мөмкин, – дип кисәтә идарә белгечләре.

«Таттехмедфарм» идарәсендә дә кайбер даруларга кытлык булуны вакытлы күренеш дип атадылар. Идарәнең матбугат хезмәткәре Лилия Никитина сүзләренә караганда, халыкны ташламалы дарулар белән тәэмин итүдә дә тоткарлыклар юк.

– Быел республикага дару кайтару буенча барлык килешүләр дә төзелгән. Дарулар безнең складларга план буенча җитәрлек күләмдә кайтарыла. Алар көн дә даруханәләргә, дәвалау оешмаларына таратыла, – дип сөйләде ул безгә.

Даруларга кытлык мәсьәләсе бу көннәрдә Хөкүмәт әгъзалары белән киңәшмәдә дә күтәрелде. Россия Президенты Владимир Путин сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуровны даруларга бәйле вазгыятьне контрольдә тотарга өндәде.

– Узган елның өч кварталында дару җитештерү 22 процентка диярлек арткан. Илебездә эшләп чыгарылган препаратларның базардагы өлеше 60 процент тәшкил итә инде. Шуңа да карамастан, кайберләренә кытлык барлыкка килгән, бәяләр арткан, – диде Путин. – Грипп чорында температура төшерә торган препаратларга, антибиотикларга ихтыяҗның зур булуын белеп торабыз. Вакытында билгеле бер запас булдырып куюга берни комачауламый. Шул хакта уйлавыгызны үтенәм. Кулланучыларыбезнең тормышын җиңеләйтер һәм базарда бернинди дә ыгы-зыгы тудырмас иде бу.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы кытлык куркынычы янаган дарулар исемлеген төзегән. «Хәвефле» исемлеккә 97 төрле дару кергән. Алар арасында күпләргә таныш «Ибупрофен», «Амоксициллин», йод, «Парацетамол», «Преднизолон», «Лоперамид», «Лидокаин» кебек дарулар да бар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Росстат идарәсе мәгълүматларына караганда, бер ел эчендә Россиядә дарулар 10 процентка кыйммәтләнгән. Белгечләр, декабрь аенда иң нык кыйммәтләнгән һәм, киресенчә, арзанайган дарулар исемлеген дә төзегән.

Кыйммәтләнгән: яшәү өчен әһәмиятле саналган дарулар исемлегенә кермәгән препаратлар (+1%), «Аципол» (+4,5%), «Ренгалин» һәм «Эргоферон» (+2,6%), поливитаминнар (+2,1%), яшәү өчен әһәмиятле саналган дарулар (+0,7%), аскорбин кислотасы (+4,5%), аспирин (+2%), панкреатин (+1,9%), омепразол (+1,5%), глицин (+1,4%).

Арзанайган: «Валидол» (–1,6%), «Афобазол» (–1,1%), «Алмагель» (–0,4%), «Смекта» (–0,3%).

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЭЧӘР СУЫМ... БАЛ ТҮГЕЛ – 2

Актаныш районының Аеш авылыннан менә мондый эчтәлектәге хат килеп иреште: «Авылда яшәүче әниебезгә кунакка кайткан идек. Эчә торган суларына шаккатып килдек. Бер көн эчендә минем кулларым җир төсенә керде. Авыр, пычрак эшләр дә эшләмәдем югыйсә, ә бары тик табак-савыт кына юдым. Савытларга, кулларыма берегеп каткан майны һич бетерә торган түгел. Шушы суны авыл халкы эчү өчен дә куллана бит. Нәрсә эшләп карарга икән безгә?» Вазгыятьне үз күзләребез белән күреп бәяләр өчен, без районга кузгалдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мазутлы, балчыклы

Аеш – Актаныштан 11 чакрым көньяктарак, Башкортстан чигендә урнашкан авыл. Биредә 320 кеше яши. Халык белән аралашкач, биредә су сыйфатының озак еллар җыелып килгән, хәзер инде чыдамаслык дәрәҗәгә җиткән проблема булуына инандык.

– Мин – шушы авылда туып, шушы нигездә үскән кеше, – дип сөйләде Аешта яшәүче Сәрмәдия Йосыпова. – 40 ел Себердә яшәгәннән соң, сигез ел элек ирем белән туган нигезгә кайттык. Безнең авылда су проблемасы гомер-гомергә булды, тик ул елдан-ел тирәнәя, суның сыйфаты начарая гына. Аеш суы бернигә яраксыз. Аны эчү түгел, хуҗалыкта да файдаланып булмый. Шуңа күрә авылга күченеп кайткач, үзебезгә скважина казытырга булдык. Тик анысы да эчәргә яраксыз булды. Тикшерткән идем, начар чыкты.

Краннан аккан суның сыйфаты начар булгач, авылда күпчелек кеше кое казыткан. Хуҗалыкка тотар өчен шуннан файдалансалар, эчәр суны күрше авыл чишмәләреннән ташыйлар икән. Фильтр куючылар да бар, тик анысы да озакка чыдамый.

– Суны фильтр белән генә яхшыртып булмый, ул бер атнага да җитми, – ди Адилә Харисова. – Аешның суы элекэлектән сап-сары иде. Тик соңгы вакытта кызыл балчыкны кара май алыштырды. Халыкның җелегенә үткән, телдән төшмәгән проблема бу.

Сәрмәдия ханымның гаиләсе дә савыт-саба юарга суны берничә кат фильтрдан чыгара. Эчәр өчен Мерәс авылыннан ташыйлар.

– Аешта чишмәләр юк. Кое казытмаган, чәйне кран суын кайнатып эчкән кешеләргә бигрәк тә авырга туры килә. Минем үземнең дә энекәшләр кран суыннан файдалана. Чәй эчкән чынаяклары каралып чыга, су торбалары ашала. Чиләкләрендә кызыл балчык чайкалып тора. Су – кешегә дә, малга да иң кирәкле әйбер бит югыйсә, – диде ул.

– Чәй эчкән чынаяк кап-кара булып кала шул. Краннан агызып алганда, суның төсе бернәрсәсе белән дә аерылмый кебек, тик зуррак савытка агызып, бераз тотсаң, ул сап-сары була. Күптән түгел генә өч фазалы фильтр алган идем. Белмим, ул җиңә алырмы икән, – диде исемен әйтергә теләмәгән тагын бер аешлы.

Халык сүзләре буенча, башнядан килгән су халык ихтыяҗларына җитми, шуңа күрә аларны елга суы белән тәэмин итәләр. Шимбә-ял көннәрендә, җәен, ягъни су күбрәк агызылган көннәрдә, сыйфаты, төсе тагын да начарлана икән.

– Суның исе дә сасы, тәме дә тәмсез. Саз тәмнәре килә, дип әйтүчеләр бар. Үземнең аннан суалчаннар, төрле бөҗәкләр чыгуын күргәнем булды. Бервакыт энекәшләрдә мунчаның кайнар су багыннан күбек чыгып күтәрелгәнен күреп, куркып киттем. Энекәш аның тозлы су булуын әйтте. Безнең әле скважина суы була торып та, 200 литрлы мичкәгә су җыелганчы, асты кап-кара ком белән тула, – диде Илфак Йосыпов.

Авыл халкы әйтүенчә, суның сыйфаты нефть аркасында начар булырга мөмкин, чөнки биредә озак еллар «кара алтын» чыгаралар.

– Узган елның октябрендә ишегалдында скважина казытырга теләп, бораулаучылар чакырган идек. 40 метрдан су чыкмады, тагын да тирәнгәрәк төшеп тә тормыйбыз, Аешта суны нефтьчеләр бозып бетерделәр, суга нефть кушылган, дип китеп бардылар, – дип әйтте Сәрмәдия Йосыпова. – Елганың икенче ягындагы урамнарда сулар чиста. Шул якта яхшы, тирән скважина казытып, су каланчасы куйсалар, проблема хәл ителмәс иде микән? Миңа калса, техник яктан хәл ителә торган мәсьәлә. Авыл буенча уза торган су торбасын да чистартырга кирәк.

Халык әйтүе буенча, Актаныш районының башка авылларында да кешеләр эчәр суга тилмерә. Аешның күршесе Кәзкәй, Качкын авылларында да суның сыйфатыннан зарландылар.

Эшлисе иде

Әлеге мәсьәлә буенча без Аеш авыл советы башлыгы Дилүс Әхәтов белән дә сөйләштек.

– Үземне дә бик борчый инде бу сорау, – диде ул. – Суның сыйфатына скважина төбендәге балчык болганып кушылу йогынты ясаган булырга мөмкин. Нефть тә булуы бар. Кайчандыр бер тикшергәндә, суның составында тимер күбрәк чыккан иде. Узган ел көзен суның сыйфаты тагын да начарланды. Моңа кадәр андый ук дәрәҗәдә түгел иде. Узган ел иске скважиналарны бераз чистартып, сууткәргеч торбаларын караган идек, ләкин аның әллә ни файдасы булмады.

Дилүс Әхәтов су сыйфатын яхшыртуның берничә юлы барлыгын әйтте.

– Аның беренчесен «Чиста су» программасы аша тормышка ашырып булады дип уйлыйм. Шуңа күрә миңа хәзер ничек тә әлеге программага керергә тырышырга иде. Икенче юлы – су чыганакларын үзебез эзләтеп карау. Быел әллә үзара салым акчасына булса да су чыганагын тикшертеп, табылган очракта, бораулап карыйм микән дип уйлыйм. Тик миңа кадәр эшләүчеләр дә берничә җирдә скважина казытып караган булганнар, яхшы су чыганагын таба алмаганнар, яки суы бик тиз беткән.

Актаныш хакимияте авыллардагы су проблемасын ничек хәл итә икән соң? Администрациянең матбугат сәркатибе Руслан Усманов әйтүенчә, районда су проблемалары «Чиста су» дәүләт программасы ярдәмендә хәл ителә. Узган ел Татарстан муниципаль берәмлекләре советы грантлары ярдәмендә 4 млн сумнан артык һәм 9 млн сум үзара салым акчасына эшләр башкарылган. Шулай ук, «аварийный запас» та шактый ярдәм иткән. Билгеле булганча, нефтьчеләрнең чишмәләрне төзекләндерү һәм суның сыйфатын саклау максатыннан махсус программалары бар. Тик моңа кадәр Актаныш аларда катнаша алмый иде. Быел исә бу мәсьәләдә зур яңалыклары бар икән.

– Актаныш, ниһаять, 2023 елдан нефть районнары сафына керде, – дип, сөенечләре белән уртаклашты Руслан. – Узган ел гына районда 520 мең тонна нефть чыгарылган, тик моңа кадәр без аларның бер генә грантларына да дәгъва кыла алмый идек. Быелдан башлап барлык авыл җирлекләре дә әлеге мөмкинлектән файдалана башлар, дип уйлыйм.

Аешта су белән проблема барлыгы көн кебек ачык булса да, авылга килеп кергәч, зарлары турында ачылып китеп сөйләрлек, тулы мәгълүмат бирерлек кешене табу җиңел булмады. Кемгә генә сүз катсак та, ярты сүздән туктап калалар, күзләрен аска төбиләр, бер-берсенә карашалар яки исемнәрен әйтергә куркалар. «Безнең бит әле монда яшисебез бар», «Авыз ачсак, пичәнсез, ашлыксыз калабыз» дигән сүзләрне дә күп ишетергә туры килде халык белән аралашканда. Проблеманың үзара гына сөйләшеп, кесә эчендә йодрык төйнәп яки социаль челтәрләрдә зарланышып кына хәл ителмәячәген күптән аңларга кирәк югыйсә. Аның өчен авыл советына да, халыкка да бердәм булып, тел яшереп калмыйча, эшне нәрсәдән дә булса башларга кирәк. Ә аңлавыбызча, проблеманы чишәргә ярдәм итү юллары бар.

Эчәргә куркыныч

Казанга кайткач, без Аештан алып килгән суны Татар төбәкара ветеринария лабораториясенә тапшырдык. Тикшерүче хезмәткәрләр шунда ук: «Анализлар начар булыр, ахры. Тышына ук чыккан. Каян таптыгыз сез моны?» – дип алып калганнар иде. Чыннан да, су анализлары көтелгән нәтиҗәләр бирде.

– Күптәннән мондый начар су белән эшләргә туры килгәне юк иде, – дип шәрехләде анализ күрсәткечләрен лабораториянең директор урынбасары Айдар Садриев. – Суның химик составы алай ук начар түгел, нормада дип әйтсәк тә була. Ә менә микробиологик анализ бик начар. Микроблар, энтерококклар, эчәк таякчыклары һәм башкалар – барысы да нормадан берничә тапкыр артып китә. Бу суны кайнатмыйча эчәргә һич ярамый, хәтта куркыныч. Кызганыч, без суның составында нефть булу-булмауны тикшермибез. Бәлки, анысы да бардыр.

КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының геология һәм гидрогеология кафедрасы доценты, фәннәр кандидаты Рөстәм Мусин әйтүенчә, нефть чыгару аркасында җир асты сулары, чыннан да, зыян күрә. Актаныш районында тикшеренүләр үткәрмәү сәбәпле, төгәл мәгълүмат әйтә алмаса да, нефть чыгып килгән кайбер районнарга тукталды. Әйтик, 1950 нче еллардан бирле нефть чыгарылган Әлмәт, Лениногорск, Баулы районнарындагы Ромашкино, Баулы, Яңа Елхово чыганаклары территорияләрендә чишмәләр күп булса да, яхшыларын табу – бик зур проблема. Мондагы чишмәләрнең суы тозлы, каты, башка микроэлементларның да тиешле нормадан артыграк булуын әйтте белгеч.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина сүзләре буенча, узган ел 10 меңгә якын кешенең эчә торган су сыйфаты яхшыртылган. Моңа сууткәргеч челтәрләр төзү, чишмәнең каптажын төзекләндерү, яңа скважиналар һәм сууткәргечләр бораулау юлы белән ирешкәннәр. Белгеч әйтүенчә, авыл халкын сыйфатлы су белән тәэмин итү, шәһәрнекеләр белән чагыштырганда, катлаулырак һәм чыгымлырак. Тикшерү нәтиҗәләре 160 мең кеше яши торган 150дән артык авылда һәм бистәдә суның катылыгы – 25 тапкыр, ә составында тимернең 10 тапкыр артып китүен күрсәткән.

– Җир асты су чыганакларын төзекләндерүгә бәйле вазгыять тә акрынлап үзгәрә, – диде ул. – Аларның һәр бишенчесе санитар таләпләргә җавап бирми. 2020 елда уникe районның 40 скважинасында санитар саклагыч зоналарын төзекләндерү буенча чаралар үткәрелде. Аңа карамастан, Мөслим, Тукай, Минзәлә, Менделеевск районнарында вазгыять катлауланды гына.

Сан

Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе мәгълүматлары буенча, узган ел Татарстанда барлыгы **31549** су пробасы алынган. Скважиналардан алынган пробаларның – **711е** (**6,7** проценты), су чыганакларының **585е** (**2,8** проценты) санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләр буенча гигиена таләпләренә җавап бирмәгән.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БАЛАМ, БАГА АЛМАМ

Илдар Мөхәммәтҗанов



ЯШӘҮ ӨЧЕН ТИЕШЛЕ ШАРТЛАР БУЛСА, НИЧӘ БАЛА ТӘРБИЯЛӘР ИДЕГЕЗ?

2 бала	37,2%
3 бала	34,6%
Төгәл әйтә алмыйм	9,6%
1 бала	7,5%
4 бала	4,5%
5 һәм аннан да күбрәк бала	3,4%
Берсе дә кирәкми	3,2%

(«Ил төбәкләренең демографик хәле-2020» социологик тикшеренү нәтиҗәсе)

< Ахыры. Башы 1 нче биттә.

Үз ризыгы белән туа...

Азалия Сафина моннан өч ел элек, «яхшы» тормыш эзләп, Яшел Үзәннән Мәскәүгә күченеп киткән. Аңа – 31 яшь, шәхси оешмада хисапчы булып эшли.

– Яшел Үзәндә әти-әни белән яшәдем. Шәһәрдә хезмәт хаклары әллә ни югары түгел. Шуңа күрә эшләгән акчам тиененә кадәр кредитка сатып алган машинама китеп барды. Тәвәккәлләп, Мәскәүгә акча эшләргә чыгып киттем. Монда мөмкинлекләр күбрәк. Үземә ошаган эшем бар. Фатирны хезмәттәшем белән бергә арендага алып торабыз. Аена 25 мең сум түлим. Аның каравы Мәскәүдә хезмәт хакым өч тапкыр диярлек күбрәк. Теләгәнемне ашыйм, рәхәтләнеп киенәм. Үзем теләгәнчә яши башлагач кына, кияүгә чыгып, бәби табыйммы? Гаилә корганчы, ныклап аякка басарга кирәк, дип саныйм. Алдагы берничә елда гаилә кору турында сүз дә булырга мөмкин түгел, – ди Азалия.

Россия икътисад университетының фәнни лабораториясе җитәкчесе Елена Егорова әйтүенчә, бер яктан, без әле дә 1990 нчы елларның демографик «упкын»ыннан чыгып җитә алмасак (ә бүген шул чор ахырында туучылар әни булу яшендә), икенче яктан, авыл, район үзәкләреннән зур шәһәрләргә чыгып киткән яшьләр бәби табарга ашыкмый.

– Яшьләр, эш, яхшырак хезмәт хакы эзләп, шәһәргә юл тота. Ә таныш түгел җиргә килеп урнашкач, гаилә кору, бәби алып кайтудан башка мәшәкатьләр дә җитәрлек, билгеле. Иң элек эш урынында үзеңне күрсәтергә, тораклы булырга кирәк. Ипотека йөге дә өстәлсә, бала табу турында уйларга вакыт та калмый, – ди белгеч.

Росстат мәгълүматларына караганда, узган елның беренче яртысында Россиядә 635 мең сабый дөньяга аваз салган. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге сан 6,3 процентка азрак. Бу – соңгы ун елда туучылар кимүнең иң зур күрсәткече, дип хафага төшкәннәр илнең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгында. 2022 елгы бәбиләрнең төгәл саны соңрак билгеле булачак. Алдан алынган фаразларга караганда, былтыр илдә 1 миллион 363 мең сабый туган. Хәтта пандемия котырган 2020 елда да 1 миллион 435 мең нарасый дөньяга килгән.

Министр урынбасары Ольга Баталина сүзләренә караганда, сугыштан соңгы чорда Россиядә иң аз туучылар 1999 елда теркәлгән. Ул елны 1 миллион 214 мең бала туган. Ә 2002 елдан башлап бәбиләр елдан-ел күбрәк туа башлаган. 2014 елда Россиядә 2 миллионга якын сабый дөньяга аваз салган әнә. Тик ул елларны сагынып искә алырга гына калмагае. 2016 елдан бирле илдә туучылар саны кимегәннән-кими. Моның беренчел сәбәпләре дә билгеле.

– Соңгы ун елда бала табу яшендәге 20–29 яшьлек хатын-кызлар 40 процентка, ягъни 4 миллион 600 мең кешегә кимеде. Андыйларның саны 2026 елдан соң гына арта башлаячак әле, – дип фаразлый министр урынбасары.

Яшь әниләр «картая»

Россия күләмендә саннар пошаманга салса да, Татарстанда бу яктан вазгыять тынычрак икән әле. Һәрхәлдә, күршеләр белән чагыштырганда, республикада яшәүче гүзәл затлар әни булу рәхәте, нәселне дәвам итү турында күбрәк уйлана. Татарстанда яңа туган бәбиләр саны гомуми күрсәткеч буенча да, бер мең кешегә алынган исәпкә караганда да, Идел буе федераль округында иң зуры. Узган елның гыйнвар – ноябрь айларында республикада 33511 сабый дөньяга аваз салган.

– Былтыр Татарстанда туган нарасыйларның 39 проценты – әти-әниләрнең тәүге шатлыгы, 36 проценты – икенче баласы, 19 проценты – өченчесе, ә 7 проценты исә – гаиләдәге дүртенче сабый. Республикада 2008 елдан бирле күпбалалы гаиләләр саны тотрыклы рәвештә арту да сөендерә, – ди Татарстан Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе җитәкчесе Гөлшат Нигъмәтуллина.

Тик уйланырлык саннар да бар. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова әйтүенчә, республикада беренче тапкыр әни булучыларның уртача яше 29га (!) җиткән.

– Ил күләмендә гүзәл затлар уртача 30 яшьтә кияүгә чыкса, Татарстанда әлеге күрсәткеч 28нче тәшкил итә, – диде ул ЗАГС идарәсенең коллегия утырышында. – Аның каравы республикада бәби алып кайтырга ашыкмыйлар. Ил күләмендә беренче тапкыр әни булучыларга уртача 28 яшь булса, бездә ул – 29 яшь.

Республикада гаилә коручылар итәк тутырып бәби дә үстергән булыр иде, бәлки, тик әти-әни булырга ашыгырга кирәк, ди ул. Чулпан Илдарханова тикшеренү нәтиҗәләрен дә тәкъдим итте. Белгечләр киләчәктә Татарстанда булачак 1–3 яшьлек сабыйлар санын фаразларга җөрьәт иткән. Әйтик, 2022 елның 1 гыйнварына әлеге күрсәткеч 130 мең булса, 2035 елда ул, 24 процентка кимеп, 99 меңне тәшкил итәр, дип көтелә.

– 2045 елда «Путин балалары» хисабына республикада 1–3 яшьлек сабыйлар саны да артып, 114 меңгә җитәр, дип фаразлана. Тик алга таба янә кимеп, 2058 елда – 91 мең, ягъни 2022 ел белән чагыштырганда, 30 процентка азрак теркәлергә мөмкин, – ди Чулпан Илдарханова.

Гаилә һәм демография үзәге мәгълүматларына караганда, Татарстанда яшәүчеләрнең 22 проценты, балалар бакчаларында урын җитмәү аркасында, әти-әни булырга ашыкмый. Саннардан күренгәнчә, бүген өч яшькә кадәр сабый тәрбияләүче әниләрнең 82 процентының гына нарасыен бакчага бирү мөмкинлеге бар. Бу уңайдан, иң яхшы күрсәткечләр Бөгелмәдә һәм Югары Осланда теркәлгән. Баланы бакчага йөртә алмыйм, дип зар елаучылар Лаеш һәм Питрәч районнарында күбрәк.

Туачак баланы яратырга кирәк

«Узган ел Татарстанда алты меңләп сабый тумады, без аларның гомерен саклап кала алган булыр идек», – ди Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының репродуктив сәламәтлек буенча штаттан тыш баш белгече, Татарстан Республикасының атказанган табибы Фирая Сабирова.

– Татарстанда туучылар саны кимүгә әти-әниләрнең сәламәтлегеннән бигрәк, социаль-икътисадый сәбәпләр күбрәк тәэсир итә, әлбәттә. Гүзәл затлар ник 29 яшькә кадәр бала алып кайтмый соң? Алар тораклы булу, карьера төзү кебек башка мәсьәләләрне хәл итәргә мәҗбүр. Ничек кенә булмасын, туучылар санын арттыру өчен өстәмә резерв бар. Мәсәлән, былтыр республикада яшәүче 12 меңгә якын хатын-кыз аборт ясаткан. Бала төшерү очракларының яртысы диярлек әни булырга теләмәү аркасында түгел, ә табиб күрсәтмәсе нигезендә ясалган. Ягъни хатын-кызның сәламәтлегенә бәйле проблемалары булуы ачыкланган. Үзегез уйлап карагыз: алдан ук тиешле чаралар күргән булсак, без былтыр 6 меңгә якын йөклелекне саклап калган булыр идек. Татарстанда яңа өйләнешкән парларга медицина сертификатларын бирә башлау да очраклы гына түгел. Аның нигезендә, булачак әти-әниләр алдан ук сәламәтлеген тикшерә алачак. Яшьләр арасында бәби алып кайтырга әзерләнү культурасы барлыкка килергә тиеш. Чөнки аборт ясату хатын-кыз сәламәтлегенә зур зыян сала, – ди белгеч.

Әти-әни булырга алдан ук әзерләнү фикерен гаилә психологы Венера Касыймова да хуплый.

– Җәмгыятьтә кыйммәтләр үзгәрде. Элек гүзәл затның әни булырга омтылуы табигый күренеш, язылмаган канун буларак кабул ителә иде. Хәзер исә әти-әни булу яшендәгеләр күбрәк үзләре өчен яшәргә күнеккән. Карьера ясап, мул тормышка җитәрлек акча тупларга, һичшиксез рульдә йөрергә, чит илләрне күрергә кирәк. Матди кыйммәтләр өстен чыкты, – ди психолог. – Ә бала табуны үз-үзеңне корбан итү кебек кабул итәләр. Чөнки төн йокламыйча бәби янында утырырга, дуслар белән күрешү урынына урамда бала арбасы тартып йөрергә, сабыйны төрледән-төрле түгәрәкләргә йөртү өчен тагын да тырышыбрак эшләргә кирәк, дип уйлыйлар. Юк, матди хәлебез начараймады. Киресенчә, бүген бишектә ятучы балалар да брендлы киемнәр генә кия. Узаң үзгәрде. Шуңа күрә үсмерләрне мәктәп эскәмиясеннән үк гаилә нигезләренә, әти-әни булырга, туачак баланы яратырга өйрәтергә кирәк.

Фикер

Сергей ГАВРИЛОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

– Бүген яшьләрне төрле пособиеләр ярдәмендә бала табарга өндәү әти-әни булырга карар кылуда хәлиткеч урын алып тормый инде. Социаль тотрыклылык һәм иминлек мөһимрәк. Халык саны кимүне тиз арада гына хәл итеп булмаячак. Гаиләләрнең иртәгәге көнгә ышанычы булырга тиеш. Шул исәптән бала тәрбияләп өйдә утыручы әниләргә түләү, оныкларын карарга әзер булган хатын-кызларны пенсиягә иртәрәк җибәрү кебек мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк.

Алмаз хәзрәт САФИН, «Өметләләр» мәчете имам-хатыйбы:

– Ислам дине күзлегеннән карап аңлатканда, гаиләдә балаларның күп булуы ул – бәрәкәт. Күпбалалы гаиләләргә Аллаһы Тәгалә көтмәгән җирдән ризыгын бирә. Шуңа күрә акча җитмәүдән һәм бөлгенлеккә төшүдән куркып, бала табудан баш тартырга кирәкми. Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә «Исра» сүрәсенең 31 нче аятендә: «Ризык җитмәүдән куркып, балаларыгызны үтермәгез. Без аларны да, сезне дә ризыкландырабыз», – дип әйтә. Бу аятьне бүгенгә бәйләсәк, хәзерге вакытта балаларны үтерү аборт ясату аша башкарыла. Коръәндә әйтелгәнчә, бу кеше үтерүгә тиң зур гөнаһ булып санала. Сүземне җөпләп әйтәсем килгән фикерем шул: татар халкы юкка чыкмасын дисәк, күп бала табу традициясен торгызырга кирәк. Моннан тыш балага биргән яхшы тәрбия әти-әнигә вафат булганнан соң да әҗер-савап китерә. Әгәр дә гаиләдә балалар күп булып, аларның һәрберсе, әти-әнисе үрнәгенә ияреп, изге гамәлләр кылсалар, моның әҗер-савабы әти-әнигә языла. Мөхәммәд пәйгамбәр әйтте: «Әгәр дә кеше үлсә, аның бөтен гамәле туктала, бары тик өч төрле гамәле өчен генә әҗер-савап язылудан туктамый. Беренчесе – савабы агып торучы сәдака, ягъни җәмгыятькә файда китерүче берәр эш эшләү, икенчесе – башкалар файдалана торган гыйлем калдыру һәм өченчесе – аның өчен дога кылучы бала тәрбияләү».

30 гыйнвар | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 2030, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ЯРАЛАНГАН ЙӨРӘК». Телесериал 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 16+
19.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
23.50 «Соотечественники» 16+
00.45 «Каравай». Кузнечная мастерская 6+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «УЕННАН УЙМАК». Телефильм 16+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Евгений Миронов, Александр Робак, Владимир Ильин. «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 Светлана Ходченкова, Александра Ребенок, Анна Банщикова, Сергей Бурунов. «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Анна Якунина, Эммануил Виторган, Ольга Павловец, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин, Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ»
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. INVICTA FC. Д. Делбони – Д. ДеКурси. Трансляция из США 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.50, 17.20, 22.25 Новости
07.05, 19.00, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Дмитрий Бивол. Путь к титулу 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Дальний Восток» 12+
13.50 «Футбол на все времена» 12+
14.25 Спортивный дайджест 0+
15.55 «Громко». Прямой эфир
17.25 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «СКА Минск» (Белоруссия) – «Чеховские медведи» (Россия). Прямая трансляция
19.25 Баскетбол 1x1. Лига Ставок – B1BOX. Прямая трансляция из Москвы.
22.30 Конный спорт. «Dubai World Cup Carnival». Трансляция из ОАЭ 0+
01.20 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Пари НН» (Нижний Новгород) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Прыжки в воду. Кубок России. Трансляция из Пензы 0+
04.40 «Громко» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Дмитрий Ульянов. «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.10 Премьера. Константин Крюков, Эдуард Флёров, Пётр Рыков, Макар Запорожский. «КРАСНЫЙ ЯР» (S) 16+
00.00 Премьера. Остросюжетный сериал «КРАСНЫЙ ЯР» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
03.00 Детектив «КРЫСОЛОВ» (S) 16+
04.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.30 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Крик» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «СИЛЬНАЯ ЖЕНЩИНА» 16+
19.00 «ПРИСЯЖНАЯ» 16+
23.15 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «НАПАРНИЦЫ». 9-я – 12-я серии 16+
03.55 «ДОРОГА, ВЕДУЩАЯ К СЧАСТЬЮ» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «НЕ ЗАБЫВАЙ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15 «ПОДКИДЫШ» 6+
10.50 «Освобождение». Документальный сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «ОФИЦЕРЫ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «За Полярным кругом» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Афёра тысячелетия. Как американцы хранят чужое золото» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ХОЗЯИН ТАЙГИ» 12+
01.05 «ГДЕ 042?» 12+
02.15 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
03.35 «ОФИЦЕРЫ». 1-я и 2-я серии 16+

31 гыйнвар | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЯРАЛАНГАН ЙӨРӘК» 12+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники». Герой России Дамир Гилемханов 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Две жизни Ильяса Дауди 16+
00.40 «Каравай». Старинные тюрко-татарские инструменты 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «УЕННАН УЙМАК». Телефильм 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Многосерийный фильм «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Анна Якунина, Эммануил Виторган, Ольга Павловец, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин и Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ»
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 17.40, 22.25 Новости
07.05, 14.25, 17.45, 18.50, 21.45, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 01.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Р. Проводников – Х. Л. Кастильо. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Что по спорту? Челябинск» 12+
13.50 «Футбол на все времена» 12+
15.55 «Ты в бане!» 12+
16.25 «География спорта. Дальний Восток» 12+
16.55, 18.10 Прыжки в воду. Кубок России. Прямая трансляция из Пензы
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Автомобилист» (Екатеринбург). Прямая трансляция
22.30 «Короли. Из гетто к победе и золоту». Документальный фильм 12+
23.45 Матч! Парад 16+
01.20 Лёгкая атлетика. «Битва полов». Трансляция из Москвы 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Прыжки в воду. Кубок России. Трансляция из Пензы 0+
05.00 «Всё о главном» 12+
05.30 «Третий тайм» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.10, 00.00 Премьера. Остросюжетный сериал «КРАСНЫЙ ЯР» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
03.00 Детектив «КРЫСОЛОВ» (S) 16+
04.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.55 «Порча». «Молоко» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА» 16+
19.00 «ТОЛЬКО ПО ЛЮБВИ» 16+
23.15 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.20 «Верну любимого» 16+
00.50 «НАПАРНИЦЫ». 13-я – 16-я серии 16+
04.00 «Давай разведёмся!» 16+
04.50 «6 кадров» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ОФИЦЕРЫ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.10 «ДЕНЬ КОМАНДИРА ДИВИЗИИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «ОФИЦЕРЫ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Миус-фронт» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ПРОПАЖА СВИДЕТЕЛЯ» 12+
02.35 «Маресьев: продолжение легенды». Документальный фильм 12+
03.25 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+
03.35 «ОФИЦЕРЫ». 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россиянең атказанган спорт мастеры, «Татарстан Республикасының Ядрә белән ату һәм стендка ату федерациясе» төбәк спорт иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Мосин** Василий Александрович; театр сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты – сәхнә остасы **Прытков** Геннадий Николаевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүләре һәм актив иҗтимагый эшчәнлекләре өчен «Камалыштагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән Бөек Ватан сугышы ветераннары: **Барабанов** Вильям Петрович, **Бушуева** Зинаида Григорьевна, **Гуревич** Розалия Зәлман кызы, **Клецко** Галина Николаевна, **Хитрина** Людмила Александровна, **Хомякова** Галина Владимировна; яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен Казан шәһәре Совет районының «П.А. Полушкин исемендәге 101 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Петрова** Татьяна Николаевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Россия почтасы» акционер җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Чистай районы почтамты 422981 Чистай почта элемтәсе бүлекчәсе почтальоны **Гайфетдинова** Рәйсә Ривгать кызына; Татарстан Республикасында «Мобиль ТелеСистемалар» гавами акционер җәмгыяте филиалының челтәр эксплуатацияләү бүлеге ярдәмче коммутация системалары эксплуатацияләү функциональ төркеме эксперты **Кондратьев** Евгений Ивановичка; «Төбәкара инфраструктура төркеме» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең техник экспертиза һәм үсеш буенча өлкән менеджеры **Уткин** Ленар Левкоевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе, Татарстан Республикасы Президентының элекке әйдәп баручы референты

ГАШИГУЛЛИН Әюп Галләм улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты ветераны

ГАШИГУЛЛИН Әюп Галләм улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы мелиораторлар коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, хатыны

ФӘЙЗӘРИЕВА Флера Зәйнетдин кызы

кинәт вафат булу сәбәпле, «Фрегат» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте элекке директоры Фәйзәриев Исмәгыйль Фәйзәри улының авыр кайгысын уртаклаша.

ТЕШКӘ КАРА КЕРСӘ...

shutterstock.com

Кариес турында сөйләгәндә, табиблар авызыннан шул сүзләрне ишетергә туры килә. Яшерен-батырын түгел, күпләр аңа бармак аша гына карый. Табиблар исә, кариесны вакытында дәваларга кирәк, дип кисәтә. Ник дигәндә, ул тешләрне бозып кына калмыйча, бик күп кенә чирләрнең башлангычы да булырга мөмкин.



Табиб-стоматолог Эльвира ХӨСӘЕНОВА белән кариес турында сөйләшәбез.

:: Кариес ул – ...

– ... тешнең каты тукымасын (дентин) акрынлап җимерүче бактерияләр җыелмасы. Алар бик тиз үрчи. Шуңа күрә алар тешне тулысынча җимереп бетерергә мөмкин. Баштарак алар тешне кырыйдан гына «ашый». Аннары тирәнгәрәк керә бара һәм ахыр чиктә аның үзәгенә (пульпа) үк төшеп җитә. Кариес сөт тешләрендә дә, төп тешләрдә дә була. Алар бер-берсеннән инфекциянең таралу тизлеге, вакыты, төре, тешнең кайсы өлешен зарарлавына бәйле рәвештә аерыла.

:: Кара таптан тыш, тештә кариес барлыгын тагын нинди билгеләр буенча чамаларга мөмкин?

– Кариес вакытында тешнең эмале каралып кына калмыйча, авыздан сасы ис тә килергә мөмкин. Баллы, ачы, салкын яки кайнар ризык капканда теш борчый башласа да, шикләнергә җирлек бар. Теш өслегендәге кытыршы урыннар да – кариесның бер билгесе. Кискен кариес вакытында теш яхшы ук авырта башлый.

:: Тештәге кариесны вакытында дәваламасаң, ни көтә?

– Кариесны азындырсаң, тора-бара тешнең эчке тукымасы ялкынсыначак (пульпит). Алга таба кариес тешнең тамырына ук зыян салачак (периодонтит). Андый чакта кешенең башы авырта, температурасы күтәрелә, хәлсезлек сизелә, тештә үлек җыела. Тукымалары ялкынсынган тешне ахыр чиктә алдырырга ук туры киләчәк. Кеше организмы һәрчак бушлыкны тутыру ягын карый. Бу очракта да, бер теш урыны бушагач, яндагы тешләр дә акрынлап урыныннан күчәчәк. Шул рәвешле тешләргә булган басым да арта. Аларның эмале зәгыйфьләнә, кителә башлый. Калган тешләр дә акрынлап сафтан чыга. Аннары тагын шунысы да бар: кариес бер тештән икенчесенә күчәргә дә мөмкин. Шуңа күрә кариесны вакытында дәваларга кирәк.

:: Ата-аналар арасында: «Баланың сөт тешләрендәге кариесны дәваларга кирәкми. Алар барыбер төшәчәк бит», – дигән фикер яши. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Бу – ялгыш фикер. Беренчедән, сөт тешләре балага ризыкны рәхәтләнеп чәйнәү, дөрес итеп туклану өчен кирәк. Шуңа күрә сөт тешләре кариес аркасында вакытыннан алда төшеп бетсә, бу баланың үсешенә дә, организмына да тискәре йогынты ясаячак. Елмайганда аермачык булып күренеп торган кискеч тешләр ярдәмендә бала иҗекләрне дөрес итеп әйтергә, сөйләшергә өйрәнә. Шуңа күрә сөт тешенең вакытыннан алда коелуы баланың сөйләмен дә бозачак. Шушы вакытлыча тешләрнең вакытыннан алда төшүе аркасында якындагы тешләр урыннарыннан күчеп, ике теш арасында зур тишекләр дә пәйда булырга мөмкин. Бу исә сөт теше урынына чыгачак төп тешләргә авырлык тудырачак. Урын җитмәгәч, алар казналык кырыеннан кәкрәеп килеп чыгарга мөмкин. Каралып беткән, ямьсез тешләр баланың үзенә дә уңайсызлык тудырачак, аның психологик халәтенә дә тискәре йогынты ясаячак. Шуңа күрә сөт тешләренә, барыбер төшәчәк дип, бармак аша карарга ярамый. Кариес күренүгә, аларны вакытында дәваларга кирәк.

КАРИЕСНЫ КИСӘТҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

✓Тешләр сау-сәламәт булсын өчен, аларны фторлы теш пастасы белән көнгә ике тапкыр, кимендә ике минут дәвамында чистартырга кирәк. Кариес тештә генә түгел, теш араларында да пәйда булырга мөмкин. Шуңа күрә аларны да даими рәвештә чистартып торырга кирәк. Моның өчен махсус җепләр бар.
✓Тәмәке һәм исерткеч эчемлекләр белән мавыгу да кариес пәйда булуга сәбәпче була ала.
✓Сагыз чәйнәргә яратучыларга аның составында шикәр булмаган төрләренә өстенлек бирергә кирәк. Тештә кариес пәйда булмасын дисәң, көндәлек туклану рационында шикәргә, җиңел углеводларга бай ризыклар булмаска тиеш.
✓Тешләрне фтор белән эшкәртү дә – кариесны кисәтүче нәтиҗәле алымнарның берсе.
✓Ярты елга бер тапкыр булса да теш табибына күренеп торырга онытмагыз. Тешләрне вакытында дәвалау, авыз куышлыгын профессиональ рәвештә чистарттырып тору мөһим.

:: Баллы ашарга яраткан кешеләрдә кариес ешрак очрый дигән сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Кариес пәйда булу-булмау нәрсә ашауашамавыннан бигрәк, тешләрне ничек тәрбияләвеңнән тора. Шуңа күрә кариесны кисәтү өчен, тешләрне даими рәвештә чистартып, теш араларын да чисталыкта тотарга кирәк. Бигрәк тә йокларга ятар алдыннан. Бу уңайдан уздырылган махсус тикшеренү барышында галимнәр көн саен йокларга ятар алдыннан даими рәвештә теш чистарткан кешенең гомере 20 елга озынаюын ачыклаган. Дөрес, тукланунын йогынтысы да юк түгел. Баллыдан баш тарту бөтен организм өчен файдалы. Кариесны кисәтү өчен сыйфатлы ризык белән тукланырга, авыз кибү, төкерек азаюга китергән авыруларны да вакытында дәваларга кирәк.

:: Сагыз кариесны кисәтергә ярдәм итә, диләр...

– Әйе, әгәр аның составында шикәр юк икән, сагыз, дөрестән дә, кариесны булдырмый калырга булыша. Чәйнәгәндә бүленеп чыккан төкерек күләме арта. Ул исә, үз чиратында, тешләргә эләгә утырырга ирек бирми, тешнең эмален җимерүче кислотаны сыегайта. Төкеректа шулай ук тешләр сәламәтлеге өчен файдалы кальций һәм фосфат күп.

Белеп чиртәсе

Көнбагыш чиртергә яратучылар җанына тынычлык алып кына калмыйча, сәламәтлеген дә яхшырта, ди белгечләр.

✷Көн саен 100 г көнбагыш төше ашау йөрәк-кан тамырлары системасы һәм бавыр авыруларыннан саклый. Ул авыр эштә эшләүчеләргә, спорт белән шөгыльләнүчеләргә файдалы.
✷Көнбагыш яра, җәрәхәтнең тизрәк төзәлүенә ярдәм итә. Шуңа күрә ул сөяк сынганда да алыштыргысыз ризык булып тора.
✷Симерүдән интеккән кешеләргә көнбагыш артык холестеринны чыгарырга булыша.
✷Көнбагыш җиңел эшкәртелә торган цинкка бай. Шуңа күрә көн саен 1 уч көнбагыш ашасаң, чәч ныгый, ялтырап тора башлый.
✷Кыздырылмаган көнбагыш йокыны яхшырта.
✷Көчле ютәл борчыганда, көнбагышны кыздырып изәләр. 2–3 аш кашыгы порошокны 0,5 литр баллы суга салып, сыеклык 0,4 литрга калганчы кайнаталар. Төнәтмәне сөзеп, ашар алдыннан көнгә 3 мәртәбә 1әр аш кашыгы кабул итәләр.
✷Кан басымы уйнаганда һәм атеросклероздан саклану өчен көнбагышны (0,5 литрлы банка белән алырга) кәстрүлгә салып, 2 литр су өстәп, шуны 2 сәгать сүрән утта кайнатырга кирәк. Төнәтмәне сөзеп, көн дәвамында эчәсе. Шул рәвешле дәвалану 2 атна дәвам итә. 5 көн ял иткәч, дәвалау курсын яңадан кабатларга мөмкин.
✷Көнбагыш сару кайнауны да баса.

Үзем сынадым

Буын сызласа

Буын сызлаудан интегәм. Соңгы арада түбәндәге ысулның файдасын күрә башладым. 200 грамм үсемлек маена 2 аш кашыгы төелгән кара борыч кушып, сүрән утта кайнатып чыгарам. Шуны 5–6 минут кайнаткач, сүндереп, суытам. Майны суыткычта саклыйм. Кулланыр алдыннан кирәк кадәрен генә бераз җылытып, авырткан урынга сеңеп беткәнче ышкырга кирәк. Җылы тукыма белән урап, бер-ике сәгать тотам. Бик яндыра башласа, тирене үсемлек маенда чылатылган мамык белән чистартырга кирәк.

Сабадан ГӨЛФИЯ апагыз

Үкчәгә сөял чыккан

1 Иң элек аякларны җылы суда тотып, тирене йомшартырга кирәк. Җебетелгән сөял өстенә салидол пластыре ябыштырып куегыз. 1–2 көннән сөял урынында кечкенә генә тишек барлыкка килсә, пластырь сөялнең тамырын суырып алган дигән сүз. Кызганыч, бер-ике айдан шул ук урында яңа сөял барлыкка килергә мөмкин. Анысын да шул ысул белән дәваларга кирәк.

2 Кайнар суда тотып йомшарган сөялгә йоклар алдыннан йомшагы белән бергә лимонның яртысын бәйләп яту да файдалы. Моны 3 төн рәттән эшләргә кирәк. Сөял йомшарачак һәм авырту да бетәчәк.

3 Лимон урынына төелгән аспирин бәйләсәң дә була. Ул да сөялне йомшарта.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

БАКЧА ЧОРЫ БАШЛАНА

Моңа кадәр «эшсезлек»тән интеккән бакчачылар өчен яңа сезон башлана. Һәвәскәр бакчачы Зөлфия ДӘҮЛӘТШИНА февраль аенда башкарырга кирәкле кайбер эшләр турында сөйләде.

1 Гадәттә грунтка утырту өчен помидор, борычларны март аенда гына чәчәләр. Ә мин февральдә утыртырга киңәш итәр идем. Кучергәнче алар тәрәзә төбендә озынаеп киткәнлектән, интегеп утыралар дип уйлыйлар. Үсентеләр бу вакытта ныгып та утыра. Февральдә чәчелгән «картайган» помидор, борычлардан грунтта ике тапкыр уңыш җыеп алырга була, ә соңрак утыртылганыннан җәй кыска килгән елны бер тапкыр да уңыш җыеп булмаска мөмкин. Чәчкәнче бер чиләк туфракка 2–3 кашык исәбеннән көл салырга, ә орлыкларны беразга гына марганцовкалы суда тотып зарарсызландырып алырга була.

2 Хәзер гөлләрне тамырландыру өчен дә кулай вакыт. Яшь ботакларны суга утыртсагыз, алар озак көттерми тамыр җәяр. Хәзер утырткан яраннар исә майга шаулап чәчәк атачак.

3 Петуния ише вак орлыклы чәчәкләрне дә, орлыктан үстерелә торган җиләкләрне дә чәчәр вакыт җитте. Хәзер аларны кар белән утырталар. Башта җылытылган әзер туфракка җылымса су сибелә, аннары аның өстенә 1,5–2 см чамасы кар түшәлә һәм өстенә орлык чәчелә. Бу – вак, куренми торган орлыкларны чәчү өчен бик кулай ысул. Чөнки күпчелек очракта петуния тишелми дию-челәр моның сәбәбен тирән утыртудан түгел, ә орлык сыйфатсыз булудан дип уйлый.

4 Хәзер бакчадагы агач-куакларны да кайгыртыр вакыт. Чөнки ачыккан кимерүчеләр бакчачылар өчен баш бәласенә әйләнә. Моннан котылу өчен нарат ботаклары белән кәүсәләрне төрергә була. Кимерүчеләр чәнечкеле мондый саклагычның үзен дә, исен дә яратмый.

ФЕВРАЛЬГӘ БАКЧАЧЫЛАР ӨЧЕН АЙ КАЛЕНДАРЕ

Чәчү өчен уңай көннәр
- Томат – 2, 3, 4, 21, 22, 23
- Кыяр – 2, 3, 4, 21, 22, 23
- Сарымсак, керән – 2, 3, 4, 7, 9, 13, 14, 17, 25, 26
- Ачы һәм баллы борыч – 2, 3, 4, 21, 22, 23
- Яшеллек өчен суган – 2, 3, 4, 7, 9, 13, 14, 17, 25, 26
- Баклажан – 2, 3, 4, 21, 22, 23
- Җир җиләге, каен җиләге – 1, 21, 22, 28
- Яшел тәмләткечләр (салат, укроп, петрушка, фенхель, кинза, шпинат, базилик, сельдерей, тмин, гәрчич) – 2, 3, 4, 21, 22, 23

Чәчәк, гөлләрне утырту өчен уңай көннәр
- Берьеллык чәчәкләр – 1, 7, 9, 28
- Ике һәм күпьеллык чәчәкләр – 1, 7, 9, 28
- Суганчалы чәчәкләр – 1, 7, 9, 28
- Бүлмә гөлләре – 1, 7, 9, 28

Гомуми
- ✓ Уңай көннәр – 1, 2, 3, 4, 7, 9, 13, 14, 17, 21, 22, 23, 25, 26, 28
- ✓ Нейтраль көннәр – 5, 8, 10, 11, 12, 15, 16, 18, 24, 27
- ✓ Уңай булмаган көннәр – 6, 19, 20

Психолог киңәше

КҮҢЕЛЕҢӘ АВЫР АЛМА

Күңелгә авыр мизгелләрдә психологлар ике кеше белән сөйләшергә киңәш итә. Берсе аның тыңлап, бөтен проблемаларыңны синең белән бергә кичереп «яндыра», икенчесе «бар нәрсә хәл ителә» дигән мәгънәдә практик киңәшләр бирә торган булсын.

1 Иртә кичтән хәерлерәк, дигәндәй, тәүлекнең теләсә кайсы вакыты булуга карамастан, бераз йоклап алыгыз. Йокы тынычландыра, нәрсәләргәдер ачыклык керткәндәй дә була.

2 Тик тормагыз, нәрсә дә булса эшләгез: язарга, юарга, җыярга, сутәргә – ягъни нәтиҗәсе озак көттерми торган берәр эш эшләргә кирәк.

3 Саф һавада йөреп керергә. Дөнья матур һәм киң: ә хәзерге мизгелдә сезнең кәефегезне төшергән хәлләр бер кыйпылчык кына.

4 Сәламәтлегегезгә зыян салмаслык күләмдә физик күнегүләр башкарырга кирәк. Монда сүз хәйләләп, 5 минут күнегү ясау турында гына бармый, ә рәхәт арыганлык кичерерлек күләмдә башкарырга киңәш ителә.

5 Күңел төшенкелегенә китергән хәлне һәр адымына кадәр күзаллап, искә төшерергә тырышыгыз. Моның җитди һәм көлке булып тоелган мизгелләрен күз алдына китерегез.

6 Кәефегезне кырган хәлгә рәхмәтле булыгыз. Бу – сезнең өчен чираттагы дәрес. Һәр дәреснең иртәме, соңмы файдасын күрми калмассыз. Кайчак кәефне кыра торган мизгелләр уңышка, бөтенләй башка юнәлешкә юл ача.

Укучы киңәше

Декабрист чәчәкләрен бик яратам. Аны чәчәк атмый диючеләргә берничә киңәшем бар. Алар зур савытларны ярат-мыйлар. Җәй көне, урамга яки верандага чыгарсагыз яхшы. Мин үзем тәрәзәләре төньякка караган верандада апрельдән салкыннар башланганчы тотам. Март аенда һәм сентябрьдә «Осмокот» дигән ашлама белән ашлыйм.

Роза РӘХИМОВА. Минзәлә

Исеңдә тот!

ШӘЛ ЮУНЫҢ ҖАЕ БАР

Мамык шәл яки «паутинка»ны юганчы яхшылап тарарга һәм селкергә кирәк. Югач утырмасын дисәгез, аны махсус киерге яки шәл размерында ясалган агач рамкада киптерергә киңәш ителә. Алдан кнопка һәм нечкә кадак әзерләп куегыз, алар белән җәймәне тарттырып, шуның өстендә дә киптерергә була.

Мамык шәлне юу өчен йон әйберләрне юу өчен махсус сыеклык, шампунь яки төс бирә торган кушылмалар катнашмаган сыек сабын кулланырга була. Мамык шәлләрне кул белән генә юарга киңәш ителә. Яхшырак агарсын дип, кер юу машинасына сала һәм гадәти порошок белән юа күрмәгез. Башта шәлне 40 градуслы җылы суда ярты сәгать тотыгыз. Бу вакыт эчендә аның пычрагы чыга. Аннары җайлап кына, кискен хәрә-

кәтләр ясамый, тарткаламый, сузгаламый гына юыгыз. Каты итеп сыкмагыз. Шәлне берничә тапкыр чайкарга киңәш ителә. Сабыны яхшылап чыгып бетсен өчен бераз суга серкә салып чайкасагыз да була. Соңгы тапкыр чайкаганда киемнәрне чайкаганда сала торган кондиционер да кулланырга мөмкин.

Тәмле булсын!

Харчо

Ләйлә КӘРИМОВА рецепты

Кирәк: *200 г сыер ите, 50 г түгәрәк дөге, 1 данә помидор, 1 аш кашыгы томат пастасы, бер кечкенә кишер, 1 литр су, 2–3 аш кашыгы вакланган әстерхан чикләвеге, 1 чәй кашыгы «Хмели-сумели» тәмләткече, 2 теш сарымсак, тәменчә тоз, кинза.*

Әзерләү: ит салып, шулпа кайнап чыккач, эре итеп туралган кишер, суган, бераз кинза салып, 30 минут кайнатырга. Кишер белән суганны шулпадан алырга. Тагын 30 минуттан итен алып турарга. Шулпага дөге салып, 15 минут пешереп алырга. Табада суган белән кишер кыздырырга, аның өстенә бер чүмеч шулпа, туралган помидор, томат пастасы салырга һәм 15 минут пешерергә. Аннары дөге кайнаган шулпага ит, табада кыздырылган әйберләрне, «Хмели-сунели» тәмләткече, әстерхан чикләвеге салып, 10 минут пешерергә. Ахырда кинза белән сарымсак салырга һәм сүндергәннән соң 10 минут тәм кертү өчен каплап тотарга.

Белеп тор!

Камыр йомшак була

Камыр ризыклары йомшак булсын дисәгез, түбәндәгеләрне истә тотыгыз.

Бодай крахмалы камыр структурасын йомшак итә, күпертә.

Газлы минераль суга бераз гына сода һәм лимон согы өстәп, камырга кушканда ул күпереп торган тыш, тиз генә искерми дә.

Көнбагыш мае камырны йомшак һәм авызда эри торган итә.

Майлылыгы югары булган каймак салынган кабартмалар искиткеч тәмле, йомшак була.

Йомырканың *агы* камырны катыра, ә *сарысы* киресенчә камырны йомшак итә.

! Икмәк һәм камыр ризыклары тиз генә бозылмасын, тәмен җуймасын дисәгез, аларны азык-төлек пленкасында һәм полиэтилен пакетта түгел, ә кәгазь пакетларда саклагыз.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

Әйткәч, үтәргә кирәк

Аллаһы Тәгаләгә биргән вәгъдәне бозу динебездә икейөзлелек буларак бәяләнә. Шуңа күрә нәзер әйткәндә бик сак булырга киңәш ителә. Әйткән нәзереңне үти алмаган очракта ни эшләргә?

«Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ нәзергә бәйле сорауларыбызга ачыклык кертте.

– Нәзер – адәм баласының үз өстенә билгеле бер йөкләмә алуы. Авыруга дучар булса, тәненә зәгыйфьлек килсә, якыны авырганда яки фаҗигагә очраганнан соң, кеше еш кына Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен берәр төрле нәзер әйтә. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан чалырмын, сәдака бирермен яисә берәр изге гамәл эшләрмен, ди ул. Нәзер – фарызга якын – вәҗиб гамәл. Шуңа күрә кеше нәзер әйткән икән, бу аның өстендә олы бурыч, йөкләмә булып тора һәм ул аны һичшиксез үтәргә бурычлы. Юкса ул аңа гөнаһ булып язылачак. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен башкарыла торган яхшы, изге гамәлләр генә нәзер итеп әйтелергә тиеш. Начар эшләр, начар ният белән нәзер әйтергә ярамый.

:: Нәзер ничек әйтелергә тиеш?
– Нәзерне әйткәндә, Аллаһы Тәгаләгә шарт куярга ярамый. Мисал өчен: «Син минем авыруымны алсаң, мин фәләнфәләнне эшлим», – дип түгел. Күп кеше нәзерне нәкъ менә шулай дип әйтә. Әмма бу безнең шәригатебездә рөхсәт ителми. Бу – мәкруһ, ягъни ярамый торган гамәл. Ул рөхсәт ителмәгән нәзер санала. Шуңа күрә нәзер әйтергә теләсәк: «Әй, Раббым, Синең ризалыгың өчен менә шушы гамәлне башкарыр идем», – дип әйтергә кирәк.

:: Әйткән нәзерне үтәүнең төгәл вакыты бармы? Ул вакыт ягыннан чикләнгәнме?
– Нәзерне үтәүнең билгеле бер вакыт чикләве юк. Әмма аны мөмкин кадәр тизрәк үтәсәң, яхшырак. Әгәр кеше нәзер әйткәндә, конкрет бер вакыт аралыгын телгә алса, ул нәзерен шул вакыт эчендә эшләргә тиеш. Әйтик, адәм баласы: «Рамазан аенда ураза тотам», – дип нәзер әйткән булса, ул нәкъ шушы айда ураза тотарга бурычлы.

:: Кеше исән чакта әйткән нәзерен үтәп өлгерә алмаса, аның нәзерен гаиләсе, туганнары үтәргә тиешме?
– Адәм баласы нәзер әйткән икән, ул тиз арада бу хакта якын кешесенә җиткерергә, бу хакта белгертергә тиеш. Бу кеше гөнаһка ирешмәсен өчен кирәк. Ул онытып җибәргән очракта туганы, дусты, якыны аңа әйткән нәзере турында искә төшерерлек булсын. Кеше билгеле бер сәбәпләр аркасында нәзерен үти алмаса яки вакытсыз бакыйлыкка күчсә, бу кешенең өстендә гөнаһ булып калмасын өчен, аның исеменнән бу нәзерне туганнары эшләргә тиеш. Нәзер үти алмау кебек күңелсез очракларны булдырмас өчен, кеше үз өстенә булдыра алырлык

vk.com

бурычларны гына йөкләргә тиеш. Эшли алмыйсың икән, нәзерне бөтенләй әйтмә.

:: Нәзерне бозу нәрсәсе белән куркыныч? Әйтик, кеше, фәлән урынга башка гомердә дә аяк басмаячакмын, дип нәзер әйтә дә, билгеле бер вакыттан кабат шунда барырга туры килә, ди.
– Безгә мондый сорау белән еш мөрәҗәгать итәләр. Кешегә, башка беркайчан күрешмәячәкмен, дип нәзер әйткән кешесе белән күрешергә, бармыйм, дигән җиренә барырга туры килсә, шаригать кануннары буенча бу адәм ун фәкыйрь яки ун мескенне туендырырга яки киендерергә тиеш. Алай эшли алмаса, ул тәүбә кылып, өч көн рәттән ураза тотарга тиеш. Шул вакытта гына ул әйткән нәзерен үтәгән булып саналачак. Болай эшләми икән, бу аңа гөнаһ булып язылачак. Нәзер әйтеп, кеше үзенә җиңеллек китерәм, Аллаһы Тәгалә миңа ярдәмен сузачак, дип уйлап ялгыша. Чөнки Аллаһы Тәгалә һәркемгә ярдәмен күрсәтә. Мин нәзер әйткәч, ул миңа күбрәк булышыр дип өметләнү – зур хата.

:: Әйткән нәзереңне онытсаң, ул һич кенә дә искә төшмәсә, ни эшләргә?
– Нәзерне онытасың икән, аны искә төшереп, төш керергә мөмкин. Аллаһы Тәгалә шул рәвешле адәм баласын гөнаһтан саклап калырга тырыша. Ибраһим галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләдән: «Ир бала бирсәң, мин аны корбан итеп чалырга да риза булыр идем», – дип сорый. Шушы нәзерен әйтә дә оныта. Күпмедер вакыт узганнан соң Аллаһы Тәгалә аңа ир бала бүләк итә. Шунда Раббыбыз Ибраһим галәйһи вә сәлләмгә әйткән нәзере турында төш аша искә төшерә. Әмма Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең каннарын түгүче түгел. «Йә, Ибраһим, Раббыңа әйткән нәзереңдә тугрылыклы булуыңны исбатладың. Аллаһ синнән разый булды. Инде корбан итеп улыңны түгел, куй чал», – дип, аңа бер сарык җибәрә. Шул рәвешле ислам динендә Корбан чалу йоласы да нәзер әйтүдән башлана. Әйткәнемчә, нәзереңне якын кешеңә әйтеп кую да мөһим. Онытκан очракта, ул ярдәмгә киләчәк.

:: Нәзере булган кеше җан бирә алмыйча тилмерер, дигән фикер яши. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?
– Юк, бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Теге дөньяга күчкәндә адәм баласы билгеле бер авырлыклар кичерә. Бу табигый. Шуңа күрә кеше үтәлмәгән нәзере аркасында җан бирә алмыйча ята дип уйларга кирәкми.

Февраль аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Чәрш	05:29	07:38	14:25	16:16	18:03
2	Пәнҗ	05:27	07:36	14:27	16:18	18:05
3	Җом	05:26	07:34	14:29	16:20	18:07
4	Шим	05:24	07:32	14:31	16:23	18:09
5	Якш	05:23	07:30	14:33	16:25	18:11
6	Дүш	05:21	07:28	14:35	16:27	18:13
7	Сиш	05:19	07:26	14:37	16:29	18:14
8	Чәрш	05:17	07:24	14:39	16:31	18:16
9	Пәнҗ	05:16	07:22	14:41	16:34	18:18
10	Җом	05:14	07:19	14:43	16:36	18:20
11	Шим	05:12	07:17	14:45	16:38	18:22
12	Якш	05:10	07:15	14:47	16:40	18:24
13	Дүш	05:08	07:13	14:49	16:42	18:26
14	Сиш	05:06	07:11	14:50	16:44	18:28
15	Чәрш	05:04	07:08	14:52	16:47	18:30
16	Пәнҗ	05:02	07:06	14:54	16:49	18:32
17	Җом	05:00	07:04	14:56	16:51	18:34
18	Шим	04:58	07:02	14:58	16:53	18:36
19	Якш	04:56	06:59	15:00	16:55	18:38
20	Дүш	04:54	06:57	15:02	16:57	18:40
21	Сиш	04:51	06:55	15:04	17:00	18:42
22	Чәрш	04:49	06:52	15:06	17:02	18:44
23	Пәнҗ	04:47	06:50	15:08	17:04	18:46
24	Җом	04:44	06:47	15:10	17:06	18:48
25	Шим	04:42	06:45	15:12	17:08	18:50
26	Якш	04:40	06:43	15:14	17:10	18:52
27	Дүш	04:37	06:40	15:16	17:12	18:54
28	Сиш	04:35	06:38	15:18	17:15	18:56

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Ислам әдәбе

Һәр мизгеле рәхмәтле

Рәҗәб аенда бөтен көнне дә ураза тотып буламы? Аерым бер көнне тотсаң да ярыймы? Шул сораулар белән «Иман нуры» мәчетенең икенче имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт ФӘЙЗУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.

«Ураза тоту мәсьәләсенә килгәндә, бу айның кайбер махсус көнендә ураза тотуны раслаучы хәдисләр юк. Рәҗәб аеның теләсә кайсы көнендә ураза тотуның гомуми сыйфатын раслаучы берничә хәдис бар, чөнки Рәҗәб – дүрт изге айның берсе. Бу айларның берсендә (рәҗәб, зөлкәгъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм) башкарылган теләсә нинди гыйбадәт кыйммәтрәк булачак. Рәҗәб аеның кайсы көнендә телисез, шул көндә ураза тотарга мөмкин», – ди ул.

Рәҗәб ае уразасына ният догасы

Рәҗәб ае уразасына ниятне үз телеңдә әйтергә дә мөмкин, гарәпчә әйтү мәҗбүри түгел. Мәсәлән болай:

«Ният кылдым таң беленгәннән алып кояш баеганчыга кадәр рәҗәб ае уразасын тотмакка».

Рәҗәб аена ифтар догасы

Рәҗәб аенда авыз ачканда укыла торган аерым догасы юк, шуңа күрә рамазан аенда укыла торганын кылырга мөмкин:

«Йә Аллаһым, шушы уразамны Үзеңнең ризалыгың өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм фәкать бер Сиңа гына бөтен эшләремне тапшырдым. Син биргән ризык белән ифтар кылдым. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, киләсе гөнаһларымны да ярлыка».

И туган тел, и матур тел...

Мин = милләт

Асыл

ГӨЛНАЗ ГАТИНА, ТАТАР, 24 ЯШЬ

Милли асыл кешенең **КҮҢЕЛЕННӘН, ТӘРБИЯСЕННӘН** киләдер дип уйлыйм. Бездә бу **ГАИЛӘДӘН** үк башлана. Милләткә, милли традицияләргә, телгә карата мәхәббәт булсын өчен әти-әни күп көч куйды дип саныйм. Әйтик, безнең гаиләдә Татарстан Конституциясе көне дә башка бәйрәмнәр кебек үк билгеләп үтелә. Безнең өчен боларны белмәү оят эш санала.

Көндәлек тормышта мин үземнең татар булуымны дәлилләп, иң элек, татар телендә сөйләшәм. «Башка җиргә күченеп китәргә теләмисеңме?» дигән сорауга да: **«МИНЕМ ТАМЫРЛАРЫМ МОНДА. МИҢА ЧИТТӘ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БАШКА КЫЕН БУЛЫР ИДЕ»**, – дип җавап бирәм. Университетта укыганда да күбрәк татар мохите булган урыннарга йөрергә тырыштым.

Кием-салымда да татарлыкны сакларга тырышам. Изү, беләзек, татар элементы кергән яулык, түштамга, алка, акча янчыгы дисеңме... Коллекциям зур! Бер караганда, бу – кечкенә генә көндәлек нәрсәләр. Әмма аларда да миллилекне күрсәтеп була һәм кирәк. **БИЗӘКЛӘР – УЛ БИТ МАТУРЛЫК КЫНА ТҮГЕЛ, Ә СИМВОЛ, МӘГЪНӘ ДӘ!** Алар аша күңел халәтен дә чагылдырып була.

Мин бик бәхетле! **ТУГАН ТЕЛЕМДӘ БЕЛЕМ АЛУ** мөмкинлеге булды. Физика, химия, биология, математиканы да татар телендә укыдым. **ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУ КЫЕНЛЫК ТУДЫРМАДЫ, КИРЕСЕНЧӘ, МИҢА БУЛЫШТЫ ГЫНА.** Бу – минем өчен «плюс» кына! Мин бөтенләй башка төрле фикерлим.

Безнең өйдә мич тә бар. Без ул мичтә бикмәк тә, коймак та пешерәбез. Безнең әти: **«ТАТАР ӨЕНДӘ МИЧ БУЛЫРГА ТИЕШ.** Анда пешкән ризык тәме дә башка», – дип әйтергә ярата.

Милләтне ярату – ул әле **«МИН – ТАТАР!» ДИП КЫЧКЫРЫП ЙӨРҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ.** Милләткә булган мәхәббәтне эш-гамәлләрең, сөйләмең, киемең, әйләнә-тирәңдәге кешеләр белән күрсәтү дөресрәк.

Туган тел – иң **КАДЕРЛЕ** нәрсә. Иң беренче сүзебезне шул телдә әйтәбез. Телне саклау өчен күпләр көч куйган. Безнең аны югалтырга бернинди **ХАКЫБЫЗ ЮК!** Туган телне саклау өчен без дә үз өлешебезне кертергә тиеш. Татар кызлары аеруча. Күпләр: «Балам татар телендә сөйләшми», – ди. Ата-анасы гаиләдә шул телдә сөйләшә икән, бала да сөйләшәчәк.

Оясында ни күрсә, очканда шул булыр. Милләткә, телгә булган мәхәббәтне балаларыма **ТАПШЫРАЧАКМЫН!** Хатын-кыз тәрбиясеннән күп нәрсә тора.

Милләт белән горурлану өчен **ӨЧ ТӨП СӘБӘП:** бай, тетрәндергеч тарихым; телем һәм миллилекнең замана белән яраклаша алуы.

МИНЕМ ДӘ МИЛЛӘТЕМ ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ КЕШЕ БУЛАСЫМ КИЛӘ!

Гөлназның көндәлек тормышында да миллилеккә урын күп. Алка, калфак, озын толым, изү... Гөлназга карап күпләр: «Чын татар кызы бу!» – дип соклана. Хәер, үзегез дә фотога карап шулай уйлап куйгансыздыр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ.

1 февраль | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.30 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «ЯРАЛАНГАН ЙӨРӘК» 12+
13.00, 04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.15 «Туган авылым» 12+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Барыс». Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Спортивная среда» 6+
00.20 «Соотечественники». Золотая рапира Владимира Житлова 16+
00.45 «Каравай». Наки Исанбет и фольклор. Часть 1-я 6+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Газинур Фарукшин турында телеочерк 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «УЕННАН УЙМАК». Телефильм 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Многосерийный фильм «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин, Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ»
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 17.50, 22.25 Новости
07.05, 14.25, 19.35, 21.55, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 01.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. А. Поветкин – М. Чарр. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Большой хоккей» 12+
13.50 «Вид сверху» 12+
15.55 Конный спорт. «Dubai World Cup Carnival». Трансляция из ОАЭ 0+
17.55 Прыжки в воду. Кубок России. Прямая трансляция из Пензы
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – МБА (Москва). Прямая трансляция
22.30 «Короли. Плоть и кровь». Документальный фильм 12+
23.45 Матч! Парад 16+
01.20 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Локомотив» (Новосибирск) – «Динамо-ЛО» (Ленинградская область) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Прыжки в воду. Кубок России. Трансляция из Пензы 0+
05.00 «Голевая неделя» 0+
05.30 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 Эмилия Спивак, Кирилл Сафонов. «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.10, 00.00 Премьера. Остросюжетный сериал «КРАСНЫЙ ЯР» (S) 16+
00.30 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
02.45 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+
04.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Орудие убийства» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ПРИСЯЖНАЯ» 16+
19.00 «ЧУЖОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
23.05 «Порча» 16+
23.40 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «НАПАРНИЦЫ». 17-я – 20-я серии 16+
03.55 «Давай разведёмся!» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ОФИЦЕРЫ». 7-я и 8-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Курляндия» 16+
19.40 «Секретные материалы». Документальный сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ПРЕДВАРИТЕЛЬНОЕ РАССЛЕДОВАНИЕ» 12+
01.15 «ТРОЙНАЯ ПРОВЕРКА» 12+
02.45 «Влюбленные в небо». Документальный фильм 12+
03.10 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+
03.25 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 1-я и 2-я серии 16+

2 февраль | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЯРАЛАНГАН ЙӨРӘК» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Рыцари вечности» 16+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – Казанга» 16+
18.00 «Юлчы» 16+
19.00, 20.00, 01.05 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Князь Тенишев 16+
00.40 «Каравай». Наки Исанбет и фольклор. Часть 2-я 6+
02.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «УЕННАН УЙМАК-2». Телефильм 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10 «Җырлый Руслан Дәминов» 6+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
00.15 «Халкым минем» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Многосерийный фильм «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Анна Якунина, Эммануил Виторган, Ольга Павловец, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин, Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ»
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 17.50, 22.25 Новости
07.05, 14.25, 17.55, 19.00, 21.30, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 01.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Д. Бивол – Ф. Валера. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Ты в бане!» 12+
13.50 «Футбол на все времена» 12+
15.55 «Что по спорту? Челябинск» 12+
16.25 «Большой хоккей» 12+
16.55, 18.25 Прыжки в воду. Кубок России. Прямая трансляция из Пензы
19.25 Футбол. «Winline. Зимний кубок РПЛ». «Ростов» (Ростов-на-Дону) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция из ОАЭ
22.30 «Короли. Воля к победе». Документальный фильм 12+
23.45 Матч! Парад 16+
01.20 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Прыжки в воду. Кубок России. Трансляция из Пензы 0+
05.00 «География спорта. Дальний Восток» 12+
05.30 «Здоровый образ. Хоккей» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.10, 00.00 Премьера. Остросюжетный сериал «КРАСНЫЙ ЯР» (S) 16+
00.30 «Поздняков» 16+
00.45 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
03.00 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Тёмная луна» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ТОЛЬКО ПО ЛЮБВИ» 16+
19.00 «БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ» 16+
23.10 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.20 «Верну любимого» 16+
00.50 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+
03.50 «Давай разведёмся!» 16+
04.40 «6 кадров» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.05 «ГОРЯЧИЙ СНЕГ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Сандомирский плацдарм» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.20 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
02.45 «ТРОЙНАЯ ПРОВЕРКА» 12+
04.20 «Живые строки войны». Документальный фильм 12+
04.45 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 5-я и 6-я серии 16+

3 февраль | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 16+
18.00 «Туган җир» 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Праздничный переполох» 16+
00.15 «ИЗВИНИТЕ, МЫ ВАС НЕ ЗАСТАЛИ» 16+
02.00 «Каравай». Возрождая национальный костюм 6+
02.25 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 16+
09.40, 15.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.30 «Казаннан – Казанга» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «УЕННАН УЙМАК-2». Телефильм 16+
16.00, 03.15 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 00.40 «Калеб» 6+
19.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фатих Хөсни турында телеочерк 16+
19.30, 22.10, 03.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
01.05 Х.Ибраһимов. «ҖИЗНӘКӘЙ». Уфа «Нур» татар дәүләт драма театры спектакле 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос. Дети». 10-й юбилейный сезон (S) (0+
23.25 «Олег Целков. Единственный из многих» 12+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу. 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Ну-ка, все вместе!» Битва сезонов 12+
23.55 Александр Демьяненко, Алексей Смирнов, Наталья Селезнёва, Юрий Никулин, Георгий Вицин, Евгений Моргунов. «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 6+
01.30 Мария Порошина, Александр Карпов, Ольга Медынич, Максим Литовченко. «ФРАНЦУЗЫ ПОД МОСКВОЙ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 17.50, 22.25 Новости
07.05, 14.25, 17.25, 18.55, 21.30, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Льюис - Спивак. Перед боем 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 01.00 «Лица страны. Арсен Галстян» 12+
13.20 «Магия большого спорта» 12+
13.50 «Футбол на все времена» 12+
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Прямая трансляция из Таиланда
17.55 Прыжки в воду. Кубок России. Прямая трансляция из Пензы
19.25 Футбол. «Winline. Зимний кубок РПЛ». «Краснодар» – «Сочи». Прямая трансляция из ОАЭ
22.30 «Короли. Чемпион никогда не сдаётся». Документальный фильм 12+
23.45 Матч! Парад 16+
01.20 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Факел» (Новый Уренгой) – «Урал» (Уфа) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Прыжки в воду. Кубок России. Трансляция из Пензы 0+
05.00 «Что по спорту? Челябинск» 12+
05.30 «Ты в бане!» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.10 Премьера. Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
00.00 «Своя правда» с Романом Бабаяном 16+
01.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.10 «Квартирный вопрос» 0+
03.05 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Забыть» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ЧУЖОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
19.00 «ТЕНИ СТАРОГО ШКАФА» 16+
23.00 «Порча» 16+
23.35 «Знахарка» 16+
00.10 «Верну любимого» 16+
00.40 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ!» 16+
03.50 «6 кадров» 16+
04.20 «МЕЛОДИЯ ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

06.25 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». 7-я и 8-я серии 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «Сталинградская битва». Документальный сериал. 1-я – 4-я серии 16+
12.45, 13.20, 15.05 «ЛЕГЕНДА ДЛЯ ОПЕРШИ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.35, 18.40 «ПРАВО НА ПОМИЛОВАНИЕ». 1-я – 4-я серии 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.00 «МЕЧЕНЫЙ АТОМ» 12+
01.50 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
03.20 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
04.50 «Покер-45. Черчилль, Рузвельт, Сталин». Документальный фильм 12+

4 февраль | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Әнвар Нургалиев 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Казаннан – Казанга» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Бар ул, бәхет, бар!» Фирая Әкбәрова 12+
15.55 «Фәрештә түгел». Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова концерты 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «Кунак БиТ шоу»16+
23.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ АМАНДЫ» 16+
00.50 «Спортивная среда» 6+
01.15 «Вехи истории». Крестьянский излом 16+
01.40 «Фәрештә түгел». Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова концерты 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк 16+
07.00, 15.05 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Кәмит Җәвит» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Күрешергә вакыт табыйк». Татарстанның халык артисты ИлСаф концерты 12+
17.10 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Фәрештә түгел». Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова концерты 16+
22.30 «Уеннан уймак». Телефильм 16+
01.00 «Җырлыйм туган якта». Илгиз Закировның иҗат кичәсе 12+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
05.05 «Халкым минем» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 К 100-летию великого режиссера Леонида Гайдая. «САМОГОНЩИКИ» 12+
10.35 «Леонид Гайдай. Век бриллиантов короля комедии» 12+
11.40, 17.15, 18.20 Фильм «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА» 0+
13.15 «КАК ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЛ ПРОФЕССИЮ» 12+
14.10 Фильм «12 СТУЛЬЕВ» (0+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.10 «Сегодня вечером» 16+
20.50 «Пес Барбос и необычный кросс» 12+
21.00 «Время»
21.35 Финал. «Снова вместе. Ледниковый период» (S) 0+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05 Агния Дитковските, Владимир Яглыч и Александр Тютин. «ТОЛЬКО ТЫ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
21.00 Премьера. Алла Юганова, Пётр Баранчеев, Елена Антипова. «НАРИСУЙ МЕНЯ СЧАСТЛИВОЙ» 12+
00.30 Мария Куликова, Владислав Резник, Алиса Авчинник, Анатолий Голуб. «ДОКТОР УЛИТКА» 12+
03.50 Анна Дубровская, Александр Дьяченко, Арнис Лицитис, Людмила Артемьева. «ЛЕШИЙ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.10, 22.35 Новости.
07.05, 12.15, 19.00, 21.30, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир.
10.05 «Команда МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.20 «БАБА ЯГА ПРОТИВ». Мультипликационный фильм 0+
10.30 «Бросок в прыжке: история Кенни Сейлорса». Документальный фильм 12+
13.00 Лыжные гонки. Матч ТВ. Гонка звёзд. Прямая трансляция из Москвы
14.25 Баскетбол. «Матч звёзд АСБ-2023». Мужчины. Прямая трансляция из Красноярска
16.25 Лыжный спорт. Фристайл. Акробатика. «Кубок чемпионов». Прямая трансляция из Красноярска
17.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
19.25 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Зенит-Казань». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Сассуоло» – «Аталанта». Прямая трансляция
01.20 Баскетбол. «Матч звёзд АСБ-2023». Женщины. Трансляция из Красноярска 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Смешанные единоборства. One FC. Трансляция из Таиланда 16+
05.00 «Всё о главном» 12+
05.30 «Третий тайм» 12+

НТВ

04.55 Детективный сериал «СТАЖЁРЫ» (S) 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 Научное расследование Сергея Малозёмова 12+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». Тайны детей звёзд 16+
23.15 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 16+
23.55 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Академия современной музыки А. Белова и О. Кормухиной (S) 16+
01.25 «Дачный ответ» 0+
02.15 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «МЕЛОДИЯ ЛЮБВИ» 16+
07.30 «НОВАЯ ЖЕНА» 16+
09.55 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ». 1-я – 8-я серии 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 140-я – 143-я серии 16+
22.25 «И РАСЦВЁЛ ПОДСОЛНУХ...» 16+
02.10 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ». 1-я – 4-я серии 16+
05.30 «Предсказания 2023» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.20 «СКАЗКА ПРО ВЛЮБЛЕННОГО МАЛЯРА» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.15 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
10.40 «Кремль-9». «Ялта 45. Тайны дворцовых переговоров» 12+
11.45 «Легенды музыки». Николай Караченцов 12+
12.10 «Легенды кино». Людмила Касаткина 12+
13.15 «Время героев». Премьера! 16+
13.35 «Главный день». «МиГ-21 и конструктор Анатолий Брунов» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 «Война миров». Документальный сериал. «Битва с фашистами за Украину» 16+
16.25, 18.25 «Великие битвы России» 16+
22.55 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ». 1-я – 4-я серии. 12+
03.35 «МЕЧЕНЫЙ АТОМ» 12+
05.10 «Вторая мировая война. Возвращая имена». Документальный фильм 12+

5 февраль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова 12+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Акыктан-ачык» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.20 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Татар халык җырлары» 0+
14.00 «Наша Республика – наше дело» 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Куньлунь Ред Стар» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
20.00, 23.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
21.30 «Болгар радиосы» концерты 12+
22.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Әнвар Нургалиев 16+
00.00 «СЛОВА» 12+
01.40 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе 6+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Харис Нигъмәтҗанов турында телеочерк 16+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20, 03.10 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе 16+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
22.00 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
02.45 «Адымнар» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 «КАК ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЛ ПРОФЕССИЮ» 12+
07.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.45 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион». Национальная лотерея (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» (0+
13.25 К 80-летию окончания Сталинградской битвы. Фильм Ю. Озерова «СТАЛИНГРАД» 12+
17.00 Специальный репортаж. «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.00 «Три аккорда». Новый сезон (S) 16+
21.00 «Время»
22.35 «КОНТЕЙНЕР» (S) 16+
23.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.15 Анна Леванова, Матвей Зубалевич, Артём Крылов. «ОДНАЖДЫ И НАВСЕГДА» 16+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 Премьера. «Большие перемены»
13.05«ТОЛЬКО ТЫ» 16+
17.00 Вести
18.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер» 12+
01.30 К 80-летию победы в Сталинградской битве. «ТУШЁНКА. СОЛОНИНА. РАЗВЕДКА» 12+
02.20 Анна Леванова, Матвей Зубалевич, Артём Крылов. «ОДНАЖДЫ И НАВСЕГДА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Л. Паломино – Д. Алерс. Трансляция из США 16+
07.00, 08.55, 12.10, 21.55 Новости
07.05, 12.15, 21.30, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Смешанные единоборства. UFC. Д. Льюис – С. Спивак. Прямая трансляция из США
13.00 Биатлон. Матч ТВ. Гонка звёзд. Прямая трансляция из Москвы
14.25 Футбол. Чемпионат Италии. «Специя» – «Наполи». Прямая трансляция
16.25 Лыжный спорт. Фристайл. Акробатика. «Кубок чемпионов». Прямая трансляция из Красноярска
17.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Штутгарт» – «Вердер». Прямая трансляция
19.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Вольфсбург» – «Бавария». Прямая трансляция
22.00 Футбол. «Winline. Зимний кубок РПЛ». Конкурсы. Трансляция из ОАЭ 0+
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Интер» – «Милан». Прямая трансляция
01.20 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Тулица» (Тульская область) 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Смешанные единоборства. UFC. Д. Льюис – С. Спивак. Трансляция из США 16+
05.00 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
05.30 «Ген победы» 12+

НТВ

04.50 «СТАЖЁРЫ» (S) 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Звезды сошлись» 16+
21.45 «Основано на реальных событиях». «Живые и мертвые» 16+
00.30 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+
04.25 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 16+
08.30 «ДАВАЙТЕ ПОЗНАКОМИМСЯ» 16+
10.40 «БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ» 16+
15.00 «ТЕНИ СТАРОГО ШКАФА» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 144-я – 147-я серии 16+
22.40 «ВЫШЕЛ ЁЖИК ИЗ ТУМАНА...» 16+
02.30 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ». 5-я – 8-я серии 16+
05.50 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.35 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ...» 12+
07.15 «В ДВУХ ШАГАХ ОТ «РАЯ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №128» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Мария Батракова 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
13.55 «НЕ ПОКИДАЙ МЕНЯ». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.40 «Легенды советского сыска». Документальный сериал 16+
20.30 «Легенды советского сыска. Годы войны». Документальный сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
01.25 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
02.35 «СКАЗКА ПРО ВЛЮБЛЕННОГО МАЛЯРА» 6+
03.50 «ЛЕГЕНДА ДЛЯ ОПЕРШИ». 1-я и 2-я серии 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 30 гыйнвар

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Гөлчәчәк Галиева. «Гәззәбану». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Хәзерге заман әдәбияты үрнәкләре». Рабит Батулла хикәяләре
15.35 Рөстәм Кутуй. «Очарга торган тузганак». Радиотамаша
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшхана»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 31 гыйнвар

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Фарида Кудашева һәм Мәгафур Хисмәтуллин концерты

Чәршәмбе, 1 февраль

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Әхмәт Гадел әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция

Пәнҗешәмбе, 2 февраль

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Нәҗия Теркулова язмалары

Җомга, 3 февраль

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Галина Казанцева концерты

Шимбә, 4 февраль

8.10 Халык җырларына багышланган әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Габдулла Тукай. «Исемдә калганнар». Радиоспектакль премьерасы

Якшәмбе, 5 февраль

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35 Мостай Кәрим. «Әҗәлгә дару бармы?» Хикәя
16.10 Константин Паустовский. «Телеграмма». Радиопостановка

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ГАЛИМ ӘХМӘТ МАЗҺАРОВ:

«ФӘН УЛ – КАНАУ КАЗУ ГЫНА ТҮГЕЛ»

Фәннең кирәге бармы? Чит илләрдән кертелгән чикләүләр яңача яшәргә өйрәттеме? Техник фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең элеккеге президенты, бу көннәрдә 80 яшьлек юбилеен билгеләп үткән Әхмәт МАЗҺАРОВ белән фәннең бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләштек.

:: Әхмәт Мазһарович, сез ничек уйлыйсыз, бүген фәнгә нәрсә җитми?

– Бик күп нәрсә җитми. 90 нчы елларда төрле өлкәдә эшләүче 6 мең гамәли институт бар иде. Хәзер алар 900ләп кенә калды. Башкаларын яптылар, инженерлар эшсез калды. Элек Фәннәр академиясендә, университетларның лабораторияләрендә фундаменталь эзләнүләр алып баралар иде. Шул нәтиҗәләрне гамәли институтларга бирәләр, алар, үз чиратында технологияләргә әйләндереп, заводларга тапшыра иде. Мәскәүдәге яшь җитәкчеләр (Гайдар, Чубайс һәм башкалар), гамәли институтларны бетереп, дөрес эшләдек, дип сөйләнә. Чит илләрдә, имеш, университетлардан турыдан-туры заводка чыгалар. Янәсе, безгә дә шулай эшләргә кирәк. Алай булмый ул. Мин шактый еллар Америка, Германия компанияләре белән хезмәттәшлек иттем, хәзер Иранда эшлим. Чыннан да, аларда университетлар бик көчле, лабораторияләрдә фундаменталь эзләнүләр алып баралар. Аларның нәтиҗәләрен компанияләргә җибәрәләр. Компанияләрнең фәнни-тикшеренү институтлары бар. Шул нәтиҗәләрне алар технологияләргә әйләндерәләр. Бездә Советлар Союзында шундый ук система иде. Гамәли институтларны ничек тә булса саклап калырга кирәк иде.

СССРда нефть эшкәртү буенча заводларыбыз беркемнекеннән дә ким булмады. Технологияләрнең 90 процентын үзебез эшләдек. Хәзер заводлар төзергә көчебез калмады. Институтлар бетте, эшләргә кеше юк. Яшь белгечләр акча күп түләнгән сәүдә, банк өлкәләренә, чит илләргә киттеләр, аларның кирәкләре калмады. Татарстанда галимнәрнең, институтларның күп өлеше сакланды. Чөнки 1991 елда Татарстан Фәннәр академиясе ачылды һәм ул галимнәрне саклап калды. Фәннең дәрәҗәсе Нобель премиясе лауреатлары саныннан күренә.

> Россиядә утыз ел эчендә бер академик Алферов лауреат булды. Аннан соң күренми, башка булмас, ахры. Россия Фәннәр академиясенең институтларын аерып, башка министрлыкка бирү дә – зур хата. Бу генералсыз армия кебек булып чыга.

Институт директоры министрлыкка акча сорап барырга мәҗбүр. Кем акча бирә, шул хуҗа. Шундый көнгә калды эш. Фундаменталь фәннең бүгенге хәле мактанырлык түгел. Федераль университетлар оештыру, аларга акча, җиһаз бирү бер яхшы адым булды анысы. Аларда үсеш бар. Тик университетлар технология ясый алмый. Яңа ысуллар табып, аны технология итеп заводка чыгару өчен, гамәли институтлар кирәк.

:: Чит илләрдән кертелгән санкцияләр яңача яшәргә, уйларга өйрәттеме? Сез җитәкләгән Волжск углеводород чималы фәнни-тикшеренү институтына ихтыяҗ арттымы?

– Чикләүләр башланганчы, яңа технология, приборларның барысын да нефть-газ акчасына чит илдән сатып алдылар. Заводларга фән кирәкмәде: акча булгач, чит илдән сатып алу җайлырак иде. Хәзер читтән бернәрсә дә сатып алып булмый. Көймәнең комга терәлүе селкенергә этәргеч булды. Галимнәрнең кирәге артты: көн саен заказлар килеп тора. Түрәләр бит алар фәнне канау казуга тиңли. Ун урынына йөз көрәк балчык атсаң, бик тиз казып була дип уйлыйлар. Фәндә алай булмый. Утыз ел буе җимерелгән фәнне өч айда гына торгызу мөмкин түгел.

Ярый әле Татарстанда фән үзәкләре калды, көчле институтлар бөтенләй бетмәде. Шуңа күрә без үзебез булдырырга тырышабыз, тик барысын да тиз генә ясап булмый. Без институтка елга 2–3 яшь белгечне эшкә алабыз. Әгәр хуҗалыкка кирәк булса, фән үсә ул. Биш-ун ел көтәргә вакытыбыз юк. 3–4 ел эчендә үзебезнең фәнне аякка бастырырга кирәк. Шул уңайдан республикада зур эшләр башкарыла. Һәр зур компания («Татнефть», «КАМАЗ») үзенең фәнни үзәген төзи. Безгә аны тиз арада эшләргә кирәк. Дөрестән дә, яңача яшәргә өйрәнеп киләбез.

«Татар-информ»

:: Сез – күкертле органик химия, нефть-газ эшкәртү, нефть, газ һәм нефть продуктларын күкертле кушылмалардан чистарту өлкәсендә бөтен дөньяга танылган күренекле галим. 40–50 ел элек чиста нефть табылса, хәзер Татарстан нефте авырая. Составы үзгәреп торгач, фәндә гел эзләнмичә булмыйдыр?

– Чыннан да, элек нефть, газ тапканда, әгәр дә анда күкерт күп булса, ул ятмаларны ябып куя идек. Хәзер андый заманалар үтте. Күкерттән куркып торып булмый. Аны таба һәм эшкәртә башладылар. Киләчәктә күкертле нефть-газ артасын һәм күкерттән чистарту проблемасын аңлап, шул эшкә тотындык. Үзем белән катализатор алып кайттым. Лабораториядә шушы эшләрне башкардык. 50 ел буе күкерттән чистарту проблемасын уңышлы хәл итәбез. Үзебезгә генә түгел, чит илләргә дә булышабыз. 1993 елны нефтьне меркаптаннан чистарту технологияләре белән Американың танылган «Шеврон» компаниясе кызыксына башлый. 100 еллык тарихы булган «Шеврон» беренче тапкыр Россиядән технология сатып алды: елына 4әр миллион тонна нефть чистарта торган ике завод төзү турында карар кабул ителде. Алар 1995 һәм 1996 елларны эшләтеп җибәрелә. Моның сәбәбе исә бик гади: Казан тәкъдим иткән технология, чыннан да, үзенең гадилеге, җиңеллеге, экологик зыянсызлыгы һәм зур чыгымнар таләп итмәве белән дөньяда кулланыла торган билгеле технологияләрдән аерылып тора. Иранда 20 ел эшлибез инде. Нефть, газ, бензин чистарту буенча алты завод эшләтеп җибәрдек.

«Татнефть»нең авыр нефтен чистарту өчен, яңа технология (ДМС-1МА) уйлап таптык. Ул технология буенча «Нурлатнефть» идарәсе елга 4 миллион тонна нефтьне күкертле водородтан чистарта.

:: Сезнең нефть һәм газ эшкәртү химиясе буенча 150ләп ачышыгыз бар. Шуның кадәр идеяләр каян килә?

– Дөрес идея килсен өчен, яхшы мәктәптә укырга кирәк. Менделеев исемендәге Мәскәү химия-технология институтында аспирантура тәмамладым. Профессор Н.Н. Лебедев фәнни мәктәбен уздым. Анда окисьлаштыру өлкәсендә эшләдем. Менә шул белемнәр нефтьнең күкертле кушылмаларына да яраклы булып чыкты. Казанга кайткач, катализатор, технологияләр уйлап табуда файдасы тиде. Бу мәктәптә укымаган булсам, мондый дәрәҗәгә ирешә алмас идем. Үзеннән-үзе галим булып булмый.

:: Булачак химикның төрле тәҗрибәләр уздырганда, нәрсәдер шартлаткан, кулларын пешергән чаклары да аз булмагандыр. Фән белән кызыксыну Балтач районының Сасна мәктәбендә укыганда башландымы?

– Мин сугыштан соң бик фәкыйрь авыл мәктәбендә укыдым. Анда химия лабораториясе, реактивлар, приборлар да юк иде. Мәктәп химиясе – тактада акбур белән аңлату. Авылда бакчада эшләү мөмкинлеге бар иде. Татар авылларында гомер-гомергә бәрәңге, суганнан башка берни үстермәгәннәр. Хатыннары йөккә узганда, безнең егетләр удмурт авылларыннан тозлы кыяр алып кайта иде. Биология укытучысы Мөхәммәтҗан абый Кильдиевны Кильди бабай дип йөртә идек. Ул мәктәп бакчасында теплица ясап, помидор, башка яшелчәләр үстерә башлады. Баксаң, Беренче Бөтендөнья сугышында Австриядә әсирлектә булган икән. Беренче тәҗрибәләр шул бакчада булды. Иң зур кабак, помидор үстереп, авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә катнаштым.

Өйдә ике яхшы укытучым булды. Берсе – әти. Ул – мулла, Кышкар мәдрәсәсенең иң яхшы шәкерте булып саналган. Әти гарәпчә, фарсыча, төрекчә, русча сөйләшә, бераз французча сукалый иде. Астрономия, математика, тарихны яхшы белә иде. Аны мулла дип каһәрләделәр. Безнең өйдә сәкедән башка берни дә юк иде. Әти һәрвакыт Коръән, китап укыды. Хәерче авыл өендә фән беренче урында булды. Китапка булган мөнәсәбәте хәзер дә күз алдында. Икенчесе – физика-математика укытучысы Мөхәммәт абыем. Миндә шушы фәннәргә карата кызыксыну уятты. Хәзер аңа – 95 яшь.

:: Сезгә Америкада эшләргә дә тәкъдимнәр булган. Чит илләрдә яши алыр идегезме?

– Чит илдә яшәр өчен яшь вакытта китәргә, анда университет бетерергә кирәк. Мәсәлән, минем ике кызым Наилә белән София, Америка, Германиядә университет тәмамлап, шунда яшиләр. 40–50 яшьтән соң читкә китүнең зарары күбрәк. Мин үз илемә, шәһәремә, милләтемә кирәклегемне тоеп яшәдем. Әгәр монда каксалар, кирәк булмасам, бәлкем, читкә китү турында да уйлаган булыр идем. Тик бу уй башыма да кереп карамады.

:: Туган телебезгә карата фикерләрегезне беләсе килә...

– Үз телеңне белмәү – җинаять, халыкка хыянәт диген сүз. Бала тугач, гаиләдә татарча сөйләшергә кирәк. Кызларым икесе дә Казанда татар мәктәбен тәмамлады. Алты тел беләләр! Бүген олысы София Лос-Анджелес шәһәрендә яши, 2018–2020 елларда шушы шәһәрнең мәшһүр университетына татар теле укытучысы итеп чакырдылар. Кече кызым Наилә – Австриядә. Алар да чит җирләрдә татар булып, үз үрнәкләре белән татар мәктәбенең юлларны кисмәвен, киресенчә, бүгенге дөньяда фикерле, акыллы, тырыш һәр кешегә барлык мөмкинлекләр дә бар икәнлекне исбатлап яшиләр. Бездә халык, татарча укысаң, надан калачаксың, дип уйлый. Алай түгел. Ике телне белсәң, өченчесен өйрәнү күпкә җайлырак. Бер тел генә белү – наданлык. Мәскәүдә зур галим академик Роберт Нигъмәтуллин бар. Кызы – Кәримә, малае Таһир исемле аның. Таһир телен татарча ачты. Бөгелмәдән бер авыз русча белмәгән татар әбиен алып килделәр, ул няня булды. Аңа карап Таһир да, Кәримә дә беркемнән дә ким түгел. Галимнең ике баласы да татарча да, русча да, инглиз һәм башкорт телләрендә дә сөйләшәләр. Үзләре – зур галимнәр. Туган телне белү – хәзинә ул. Без Роберт белән һәрвакыт мөнбәрләрдән, туган телне белергә кирәк, дип әйтеп килдек.

> Зур җыелышларда хәзер мин, балаларыгызны татарча сөйләшергә өйрәтегез, дип сөйлим. Чит илгә чыккач, бөтен җирдә дә татарча сөйләшәм. Бөтен капкалар ачык.

:: Тормышыгызда тайпылышсыз үтәлә торган кагыйдәләр бармы?

– Ялкау булмаска, бер минутны да әрәм итмәскә! Безгә әти шуны сеңдерде. Һәр минутта белемне, сәламәтлегеңне арттыру өчен эшләргә кирәк.

:: Сезгә күптән түгел 80 яшь тулды. Күз тимәсен, сез сиксәндә дә төз гәүдәле, яшь күренәсез, егетләр кебек әле. Сере нәрсәдә?

– Сере бик гади – хәрәкәттә, сәламәтлекнең кадерен аңлауда. Гомер буе чаңгы шудым, байдаркада йөздем. Хәзер дә көн саен җәяү йөрим. Тәмәке тартмадым. Бары шул гына.

Әңгәмәдәш – Сәрия МИФТАХОВА

Эльвира ВӘЛИЕВА

СОРЫЙ БЕЛЕП СОРАСАҢ

Акча арта! 1 февральдән ил күләмендә кырыктан артык социаль түләү күләме артачак. Субсидия, пособиеләрне уртача 12 процентка кадәр күтәрергә вәгъдә итәләр. Кемгә күпме акча тиеш? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

Пособие үсә

Илнең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы агымдагы елның 1 февраленнән социаль түләүләрне арттыру турында хәбәр итте. Былтыргы инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, гамәлдә булган 40тан артык ярдәм чарасы индексацияләнәчәк дип көтелә. Социаль түләүләр уртача 11,9 процентка кадәр артачак. Гади сүз белән әйткәндә, узган ел куллануучылар бәяләре әнә шулкадәр үскән. Хәзер исә социаль түләүләрне әлеге күрсәткеч белән тәңгәлләштерәчәкләр.

1 февральдән бала туганда бирелә торган бердәм пособие, балаларга айлык түләү, ана капиталы, ветераннарга айлык акча кебек түләүләр артачак. Аерым алганда, быелдан гаиләдә туган беренче балага ана капиталы 587 мең сумга җитәчәк. Узган ел белән чагыштырганда, әлеге төр түләү 62500 сумга артачак.

Шактый еллар «катырылып» торганнан соң, кабат үсә башлагангамы, ана капиталы тирәсендә фикер-тәкъдимнәр дә артты. Бигрәк тә депутатлар баш вата. Әле бу көннәрдә генә Россия Дәүләт Думасында ана капиталына торак сатып алганда, әти-әниләрне сабыйга «өлеш» бүлеп бирүдән азат итәргә тәкъдим иттеләр. Бу хакта закон проекты да әзерләгәннәр. Эш шунда ки, ана капиталы акчасын кертеп алган торакны сатарга теләүчеләргә шактый тир түгәргә туры килә. Чөнки балигъ булмаган бала акчасын тоттыңмы, син аңа шул фатирда «өлеш» бүлеп бирергә тиеш. Ә бер кул белән биргәнне икенче кул белән алу өчен Опека һәм попечительлек органыннан рөхсәт кирәк. Бала хокукларына бәйле барлык шартларны үтәгән очракта да, әлеге эш ике-өч айга кадәр сузылырга мөмкин.

Депутатлар әйтүенчә, яшь гаиләләр нигездә торак шартларын яхшырту өчен бер фатирны икенчесенә алмаштыра. Ә ана капиталы акчасы бу эшне тоткарлый. Өстәвенә бала документларын рәсмиләштерү бик чыгымлы да әле. Үз башыбыздан узгач, соңгысы белән килешмичә дә булмый. Моннан өч ел элек ана капиталы акчасы кергән ике бүлмәле фатирны «өчле»гә алмаштырганда, нотариус аша бала документларын рәсмиләштерү өчен генә дә 25 мең сум акча түләргә туры килде.

Ялыкка каршы чыгучылар да бар. Федераль нотариаль палата белгечләре сүзләренә караганда, бүген балага «өлеш» бүлеп бирү мәҗбүри саналганда да, әти-әниләр арасында моны эшләргә ашыкмаучылар җитәрлек. «Нәтиҗәдә бала хокукларын яклап суд бусагасын таптарга туры килә. Бу эшне ирекле итеп калдырсалар, баланың үз почмагын булдыру турында, гомумән дә, онытачаклар. Ахыр чиктә, бала ярык тагарак янында утырып калачак», – дигәннәр нотариаль палатада.

Идар Мөхәммәтҗанов

Сан

Татарстанда ана капиталына ия булган гаиләләрнең **86** проценты акчаны яшәү шартларын яхшыртуга юнәлткән.

Өч квадрат метрлы... ярдәм

Ана капиталына тияргә ярамый тимәскә! Бу җөмләдә өтерне кая куярга икәнен якын арада үк хәл итәргә туры килер, мөгаен. Россия Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисе урынбасары Яна Лантратова ана капиталын ел башында шактый кыйммәтләнгән коммуналь түләүләргә тотарга тәкъдим итте әнә. «Ут-суга бәяләр артты, ә яшь гаиләләрнең барлык төр чыгымнарга акчасы җитми, бурычлары җыела. Кайбер мәгълүматлар буенча, коммуналь түләүләргә елына 100 мең сумга кадәр акча тотучы гаиләләр дә бар. Шуңа күрә ана капиталын куллану мөмкинлекләрен арттырып, аны коммуналь түләүләргә тотарга да рөхсәт итәргә кирәк», – дигән депутат. Мондый закон проектын хуплаулары бик шикле, әлбәттә.

Ул арада күчемсез милек агентлыгы белгечләре бала акчасын бизмәнгә салып «үлчәп» караган. Белгечләр илнең төрле шәһәрләрендә ана капиталына ничә квадрат метр торак сатып алырга мөмкин икәнен ачыклаган. Беренче урында – Чиләбе. Бу шәһәрдә яшь гаиләләр ана капиталы акчасына 8 квадрат метр торак сатып алу бәхетенә ия икән. Икенче урында – Волгоград (6,6 квадрат метр). Беренче өчлеккә Омск та (6,5 квадрат метр) эләккән. Казан беренче бишлектә дә, хәтта беренче унлыкта да юк. Татарстан башкаласында ана капиталы акчасына якынча 3 квадрат метр торак сатып алырга мөмкин. Мәскәүдә бала почмагы – 1,7 квадрат метр, ә Санкт-Петербургта исә 2,8 квадрат метр тәшкил итә, дигәннәр. Менә шундый ярдәм!

Хатын-кызларга кирәгрәк

2022 елның 31 декабрендә мәгълүм булган халык санын исәпкә алу нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда яшәүче һәр дүрт кешенең берсе пособие һәм субсидияләр хисабына көн күрә. Җанисәптә катнашучылар әнә шулай дигән. Росстат игълан иткән саннардан күренгәнчә, Татарстанда дүрт миллионнан артык кеше яши. Алардан керем чыганаклары турында да сораганнар. Республикада яшәүче 1 миллион 100 меңгә якын кеше пенсия, пособие, стипендия кебек дәүләт һәм оешмалардан түләнүче акчага яшәвен әйткән. Андыйлар арасында, пенсионерлар һәм студентлардан тыш, эшкә сәләтле яшьтәге 200 меңнән артык кеше дә бар.

«Социаль түләүләр хисабына яшим», – дип җавап бирүчеләр арасында хатын-кызлар күбрәк. Аларның да зур күпчелеге, тәгаен әйтсәк, 68 проценты шәһәрдә яши. Әллә авыл халкы артык тыйнакмы, әллә җанисәп алучылар салага кадәр барып җитмәгәнме? Бу сорау ачык кала. Республикадагы 240 меңгә якын кеше: «Башкалар акчасына яшим», – дигән. Аңлашыла ки, бу – нигездә, гүзәл затлар. Авыллар белән чагыштырганда, шәһәрдә хуҗабикәләр саны өч тапкыр күбрәк.

– Ике яшьлек бала белән декрет ялында утырам, – ди Яшел Үзәндә яшәүче Айгөл Зиннәтуллина. – Безнең гаиләдә дүрт кеше. Олы улым дүртенче сыйныфта укый. Гаиләне ирем туендыра. Аның рәсми эш урынында хезмәт хакы югары түгел. Шуңа күрә берничә урында эшләргә туры килә. Балаларның икесенә дә пособие алам, моннан тыш коммуналь түләүләр өчен, аз керемлелек буенча субсидия килә. Дәүләт ярдәме аена 30 мең сумга кадәр җитә. Кыш көне аннан да күбрәк түлиләр. Моннан тыш, елга ике тапкыр балаларга дару сатып алырга дип банк картасына 5 мең сум акча күчерәләр. Социаль ярдәм чаралары күп төрле, белергә генә кирәк.

Белгеч сүзе

Казанның Идел буе районының социаль яклау бүлеге белгече Альбина МУСИНА:
– Балаларга пособие билгеләү өчен, мәсәлән, яшь гаиләләрнең керемнәреннән тыш, торак шартлары да игътибарга алына. Гаиләдә җан башына туры килгән квадрат метр күләме тиешле нормадан артып китә икән, дәүләт ярдәме түләнмәячәк. Узган ел ахырында аз керемле гаиләләргә Яңа елдан соң балигъ булмаган һәр балага ун мең сум акча бирәчәкләр икән, дигән хәбәр таралганнан соң, безгә шул хакта сорап килүчеләр дә шактый. Бу – яңа бердәм түләү кертелүгә бәйле аңлашылмаучанлык кына, өстәмә түләү юк. Бала пособиеләренә бәйле сораулар буенча Социаль фондка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге мәгълүматы:
– Гыйнвар башыннан бирле республикада яшәүче 50 меңгә якын кеше йөкле хатын-кызлар һәм 17 яшькә кадәр балалары булган гаиләләргә бердәм пособиегә гариза тапшырган. Билгеле булганча, яңа төр түләү 1 гыйнвардан гамәлгә керде.

Бердәм пособие аз керемле гаиләләргә моңа кадәр гамәлдә булган ярдәм чараларын берләштерде. Болар – гаиләдә беренче балага 3 яшькә кадәр түләү, 3 яшьтән алып 8 яшькә кадәр һәм 8 яшьтән алып 17 яшькә кадәр балаларга пособиеләр һәм йөклелек буенча айлык акча. Яңа пособие керем дәрәҗәсе Татарстанда билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләргә бирелә. Исегезгә төшерәбез: республикада әлеге күрсәткеч 12 мең 219 сум тәшкил итә.

Фикер

Мария ФИЛИППОВА, социолог:
– Социаль түләүләргә генә өмет итеп яшәү безнең халыкка хас күренеш түгел. Шуңа күрә җанисәп нәтиҗәләрен шартлы рәвештә генә кабул итәргә кирәк. Күпчелек өстәмә керем чыганагы турында, гомумән, әйтмәгән булырга мөмкин. Чөнки әлеге мәгълүмат салым хезмәтенә китәчәк, дип шикләнәләр. Күпме хезмәт хакы алуыңны беренче тапкыр күргән кешегә түгел, таныш-белешләргә дә әйтеп бетермисең әле. Бу – четерекле мәсьәлә. Халыкның матди хәле турында керемнәргә түгел, ә чыгымнарга карап фикер йөртү дөресрәк. Казан – ил күләмендә иң кыйммәтле шәһәрләр арасында. Шул ук фатир бәяләре, мәсәлән, юктан гына артмый. Тәкъдимне сорау барлыкка китерә. Татарстанда хезмәт хаклары шактый югары. Ә социаль түләүләр – иң беренче чиратта, аз керемле гаиләләргә, өлкән яшьтәгеләргә төп ярдәм чарасы.

2023 елның 1 февраленнән социаль түләүләр күпмегә арта? (мең сум)

1 февральгә кадәр	Түләү	1 февральдән соң
524,5	Беренче балага ана капиталы	**586,9**
693,1	Икенче балага ана капиталы (беренче балага алынмаган булса)	**775,5**
168,6	Икенче балага ана капиталы (беренче балага алынган булса)	**188,6**
20,4	Бала тугангa бердәм пособие	**22,9**
7,6	Яшь ярымга кадәр бала тәрбияләгән өчен пособие (минималь күләме)	**8,5**
74,6	Россия Геройлары, Советлар Союзы һәм Дан орденының тулы кавалерларына түләү	**83,5**
55	Хезмәт геройларына түләү	**61,5**
6,9	Җирләү өчен социаль түләү	**7,7**
3,1	Чернобыль инвалидларына һәм Чернобыль АЭСында авария нәтиҗәләрен юкка чыгаручыларга пособие	**3,5**
117,7	Сәнәгатьтә имгәнү очрагында бердәм түләү (максималь күләме)	**131,7**

СОҢГА КАЛМАСКА ИДЕ!

Шәледә гомер итүче Тәнзилә Сәйфетдинова бүген шушы уй белән яши. Аның 17 яшьлек улы Илсафны сәламәт егет итеп күрәсе килә. Юкса инде тормыш төрле яклап сынаган да үзләрен. Ирсез калып, ике баланы аякка бастыруы, хатын-кыз башы белән өй җиткерү дә – үзе бер сынау югыйсә. Әмма күрәселәре моның белән генә бетмәгән икән.

– Ирем Ирек белән матур тордык. Кызганыч, гомере генә кыска булып чыкты. Ике улыбыз белән мине ялгыз калдырып, 35 яшендә йөрәк авыруыннан үлеп китте, – дип искә ала Тәнзилә. – Әтисе үлгәндә, олы улыбыз Илсафка – 12, кечесенә 6 яшь иде. Бик авыр көннәр булды. Җитмәсә, йорт җиткезә башлаган идек. «Нишләргә соң?» – дип, озак баш ваттым. Ышанмассыз, яныма утыртып да улым Илсаф белән киңәштем. Баланың Шәледә каласы килде.

Илсаф 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, Казанга көллияткә укырга керә. Әйбәт кенә укып йөргән җиреннән колак авыртуына зарлана башлый. Тизрәк табибка баралар. Анда исә МРТ узарга кушалар.

– Табиблар улымны ике сәгать буе тикшерде. Аннары исә куркыныч хәбәр җиткерделәр: улымның башында шеш бар икән. ДРКБда табиблар Мәскәүгә барып тикшеренергә киңәш итте. Берничә урында күрендек, барысы да шул киңәшне бирә, – дип сөйли Тәнзилә. – Күптән түгел мин янадан кияүгә чыккан идем. Бер ай элек уртак балабыз туды. Кулымда кечкенә сабый булгач, өйдән дә чыгып китеп булмый. Әле ярый Илсафның әтисенең туганнары ташламый.

Мәскәү табибларына хәзер үк күренү өчен акча кирәк. Бушлай юлламаны берничә ай көтәсе. Әлбәттә инде, Илсафның да, әнисе Тәнзиләнең дә тизрәк тикшеренү узып, куркудан арынасы килә. Табиблар тикшерә торгач, шешнең колак өстендә урнашуын, аны башына операция ясап кына алып буласын әйткәннәр. Җитмәсә, күзләренең дә күрүе начарлана башлаган.

– Улым кечкенәдән сабыр булды. Әчендә ут янса да, сиздерми ул. Артыгын сөйләшми дә, бар нәрсәне әченә җыя. Операциягә кирәргә дә риза үзе. Сихәтләнә аласына бик тә ышана, – ди Тәнзилә. – Кешедән сорамыйча башка чарам юк. Баламны савыктырырга булышсагыз иде.

Илсафка ярдәм итәргә теләүчеләр өчен әнисе Тәнзилә Тәлгать кызы Сәйфетдинова исемендәге Саклык (Сбер) һәм "Ак Барс" банкы картасы номерлары **89534930325** телефонына беркетелгән.

ҖИҢҮЧЕ ӘМИНӘ

Өмет һәм үҗәтлек. Саба районының Шәмәрдән авылында яшәүче 12 яшьлек Әминә Закирҗанова Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннарында фигуралы шуу буенча беренче урынны алды. Биш яшеннән спорт белән шөгыльләнгән баланың беренче зур җиңүе бу! Әнисе Фәридә әйтүенчә, Әминә – герой ул! Ә мин исә әнисенең дә батыр йөрәкле булуына инандым.

Фәридә белән Рәшит Закирҗановлар кызлары Әминәне 20 ел көтә. Гаилә корып яши башлауга, башкалар кебек бәби сөю теләге белән яна башлый алар. «Әле бәби алып кайтмыйсызмы?» – диючеләр дә күп була. Явыз телләләр кирәкмәгән сүзләр дә ишеттерергә күп сорамый. Кешегә сиздермәсәләр дә, йөрәкләре яна үзләренең. Кая гына йөрмиләр алар. Хастаханәләрдән дә кайтып кермиләр, багучының да ишеген шакыйлар, әшкерүчеләргә дә йөриләр. Тик нәтиҗәсе генә булмый.

– Бер әбигә бардык. Ул безне карады да, сезгә табиблар булышачак, кыз балагызны күрәм, диде. Шушы сүз өмет уятты. Шуннан соң без тагын кат-кат тикшерендек. Бәби таба алмавыма үземне гаепли идем. Башка төрле уйлар килде. Күп тапкыр иремә дә, аерылышыйк, башкага өйләнеп карасаң, бала сөяр идең, дидем. Тик Рәшит беркая да китмәде. Миңа да каты бәрелмәде. Яратуы көчле булган инде. Минем аңа карата яратуым, хөрмәтем һәм ихтирамым бик зур, – ди Фәридә.

Ул әле дә иренең һәм аның туганнарының яхшы мөнәсәбәтен искә ала. Берәү дә күңелен рәнҗетми аның. Сабыр итеп, озак еллар сыналгач, Фәридә 45 яшендә ЭКОга бара. Табиблар, бераз көтсәгез, үзең дә узачаксың, дип өметләндерә. Әмма Фәридә көтми. Вакыт бара, аның тизрәк әни булу бәхетен татыйсы килә. Шулай итеп, могҗизалы көн килеп җитә. Фәридәнең карынында берьюлы ике сабый барлыгы ачыклана. Бәби күтәрү җиңелдән бирелми. 26 атнадан сабыйлар дөньяга аваз сала.

– Балаларым җитлекмичә туды. Берсенә 10 гына көн яшәп калу насыйп булган икән. Бар өметем һәм мәхәббәтемне икенчесенә бирергә тырыштым. Аның авырулары да, сулыш ала алмавы да мөһим түгел. Үземнең йөрәк ярсып тибә, очып кына йөрим. Мин – әни! – дип искә ала Фәридә. – Дөрес, табиблар артык өметләндермәде. Миңа барысына да әзер торырга киңәш иттеләр. Әминә кызым өч ай буе аппарат астында ятты. Биш тапкыр йөрәге туктап калды. Җитди операцияләр узарга туры килде. Әмма мин беркайчан да үкенмәдем. Күпме генә авырлык кичерсәм дә, сабыр иттем. Әни булу бәхете биргән өчен Аллаһы Тәгаләгә бик рәхмәтле идем. Сабыем исән булсын иде, дип догалар укыдым. Ирем һәм каенанам төп терәгем булды. Алар һәрвакыт ярдәм итте. Кызымны өйгә алып кайтканда, табиблар әйткән куркыныч сүзләрне хастаханә ишегеннән чыкканда ук оныттым.

Кечкенә Әминә бөтен гаиләне берләштерә. Вакытвакыт дәвалау курслары да үтә алар. Дөрес, җитлекмичә туган бала үзен сиздерә инде. Әмма әнисе кулдан килгәннең барысын да эшли. Азапланыу, үзе биргән сабыйны рәхмәтле булып кабул итеп алуы, аның өчен тырышуы өчен Аллаһы Тәгалә Фәридәгә көтмәгән бүләк бирә: 48 яшендә бәбигә уза ул. Табибларның коты оча, күтәрә алмаячаксың, диләр. Әмма Фәридә үзенең кулындагы бәхетен ычкындыра торганнардан түгел. 9 ай карынында йөртеп, тупырдап торган тагын бер кыз алып кайта ул. Аңа Мәдинә дип исем кушалар. Фәридәнең шушы яшендә курыкмыйча бәби табуын күпләр батырлыкка тиңли, аңлап бетермәүчеләр дә була.

– Мәдинәбез тугач, тормышыбыз тагын да түгәрәкләнде. Мин бөтенләй яшәрдем. Йөрәк хисләрдән тулып торды. Әле хәзер дә шулай. Мин үземне дөньядагы иң бәхетле әни саныйм, – ди Фәридә. – Ике балам да бик кадерле миңа. Ару-талуны да белмим. Әминәмнең аяк-куллары көчсезрәк иде. Шуннан ничек котылып була икән дип эзләнә башладым. Йөзүгә бирмәкче идем. Әмма пульмонолог, сезгә боз кирәк, диде. Баксаң, минеке кебек сабыйларга тимераякта шуу ярдәм итә икән. Бу хакта белгәч, Сабага Казаннан килеп дәресләр үткәрүче Анна Романованы эзләп таптык. Ул чакларны искә алсам, шаккатам. Нәзек кенә куллы, җиңел гәүдәле баламны ничек кабул итеп алды икән ул?! Миңа күрсәтмәсә дә, эчендә курку булгандыр инде. Баланы шуарга өйрәткәндә үзәмә дә бозга басарга туры килде. Җайлап кына өйрәтергә туры килде. Әминә – бик хисле бала. Борчылган чакларында юатып кына торабыз. Мин аны кадерләп-саклап кына яшәтәм. Кайчак арып та китә. Андый чакларда, укытучылары белән киңәшеп, өйдә ял иттереп алам.

Шөкер, Әминә – булдыра торган кыз. Оста итеп шигырьләр дә сөйли, бик актив. Өйдәге эшләрне дә ялт итеп эшләп куя икән. «Әни, нишлим?» – дип кенә тора, ди Фәридә. Ул кызларын бөтен эшкә өйрәтә. Ашарга да пешерә беләләр, өйне дә җыештыралар.

– Мин аларны тормышка әзерлим. Бер генә теләк – янәшәләрендә озак еллар була алсам иде, – ди ул.

Фәридәгә – 57 яшь. «Үз яшьтәшләрем белән түгел, аларның балалары белән уртак тел табам. Үземне алар кебек итеп тоям. Яшем турында уйлаганым да юк, исәнлегем генә булсын», – ди ул.

Фәридә Закирҗанованың шәхси архивыннан

Без аның белән Әминәнең җиңүе турында сөйләшәсе идек бит. Әнисе сүзне кыска тота – аның өчен тренерга шалтыратырга кирәк, ди ул. Әмма кызы өчен бик горурланун яшерми. Моңа кадәр яше җитмәгәнгә спорт ярышларында катнаша алмаган кызы, быел беренче тапкыр чыгыш ясап, беренчелекне алсын әле! Әлегә Әминә җиңүен аңлап та бетермәгән. Үзенә булган игътибардан каушап та калган. Тренеры Анна Романова исә, кызның җиңүендә әти-әнисенең өлеше зур, ди.

– Әминә 8 ел буе шөгыльләнә. Әнисе аны безгә алып килеп бик зур эш башкарды. Дөрес юл күрсәтү дә кирәк. Андый балалар өчен фигуралы шуу тернәкләндерү чарасы да әле ул, – ди тренеры. – Әминә катлаулы программаны югары дәрәҗәдә башкарып чыкты. Мин Әминәгә ышанам. Ул бик тыңлаучан, максатчан бала. Яңа үрләре алда әле аның!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РӘСИМ НИЗАМОВ:

«ХӘЗЕР, СӘХНӘГӘ ЧЫГАР ӨЧЕН, ТАМАДА БУЛУ ДА ҖИТӘ»

Үзенә – 50, сәхнә иҗатына – 25! Татарстанның халык артисты Рәсим НИЗАМОВ өчен быел әнә шундый истәлекле дә, җаваплы да ел. Сәнгать нинди үзгәрешләр кичерә? Популярлыкның асылы нәрсәдә? Ертык җырлар һәм артист күчермәләре ни өчен барлыкка килә? Без әнә шулар хакында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Хәзерге эстрада белән элеккесе арасында аерма зурмы? Нинди сыйфатлар югалды, нindиләре өстәлде?

– Хәзерге белән аерма шунда: ул чакта җырчы булу өчен белем алырга, конкурслар юлын үтәргә кирәк иде. Укыган вакытым туксанынчы елларга туры килде һәм әле ул чакта да шушы «совет мәктәбе» сакланган иде. Бүген исә профессионаллар белән үзешчәннәр арасында аерма юкка чыкты. Элек җырчы булу өчен укырга кирәк иде, хәзер тамада булу да җитә. Сәхнәгә җиңел карый башладык. Аның дәрәҗәсен төшерүдә үзебезнең дә гаеп бар. Үзебез, дигәндә, мин тулаем халыкны күз уңында тотам.

> Ә бит кайчан гына өлкән буын җырчылар: «Сәхнә ул – изге урын», – дип әйтә иде. Хәзер исә ул тамада дәрәҗәсендәге күңел ачу чарасына әйләнеп калды. Җыр сәнгатенең ни дәрәҗәдә төшкәнен сез инде үзегез дә беләсез. Ә инде аның бурычларына килсәк, иң беренчесе һәм әһәмиятлесе җыр белән тәрбияләү иде. Без халыкны тәрбияләргә тиеш идек. Менә бу функция югалды.

:: Артист – иярүчеме, ияртүчеме?

– Без иярткүче идек, тамада дәрәҗәсенә төшеп, иярүчегә әйләнеп калдык. Нәрсә сөйләсәм дә, нәрсә җырласам да ярый, дип уйлый күпчелек. Журналистлар сөйләм культурасын кайгырткан кебек, без дә җырлау культурасын кайгыртырга тиеш. Ул нәкъ шул ук, алар аерылмый да.

:: Танылу өчен, нинди сыйфатларга ия булырга кирәк? Һәм шул танылуны озак елларга саклап калу өчен нишләргә?

– Танылып, билгеле бер баскычны яулагансың икән, шул дәрәҗәне саклау – иң авыры. Артист җырлаудан туктамаса, җырласа, эзләнсә, яуланган үрне саклау да бик үк авыр түгел. Мин үзем дә тамашачы буларак концертларга йөрим. Дөрес, элек күбрәк йөри идем, хәзер сирәгрәк. Чөнки тыңлап булырдайлары күп түгел. Ә инде залдан чыгып киткәндә, 15–20 җырның берсе күңелгә кереп кала һәм син аның көен көйләп кайтып китәсең икән, димәк, концерт бушка узмаган. Шоуны корырга була аны, ә менә күңелгә үтеп керердәй җыр иҗат итү... Анысы тансыкка гына килеп чыга.

Бүген күп җырчылар сәхнәгә омтыла. Бәлкем, барысын да җырчы дип әйтергә кирәкмидер дә. Дөрес, бу омтылыш бер яктан яхшы, икенче яктан вагайта. Әгәр сәхнәгә омтылган кеше шул юнәлештә даими эшли һәм үз җырын тапканчы эзләнә икән, ул сәхнәдә үз урынын таба. Бер җыр белән таныла җырчы. Шул җыр алып кереп китә аны. Шул җырга ияреп, башка җырлар китә.

:: Сезне «Каеннар арасында» дигән җыр танытты, дисәк, дөрес булырмы? Һәм тәнкыйтьләнгән җыр да шушы бугай. Үзегез ни уйлыйсыз?

– Шулай диләр шул. Башка җырларым булса да, бу хәл миңа ошаса, ошамаса да, әлеге фактны берни эшләтеп булмый. Тәнкыйтькә килгәндә, аның максаты да шул иде. Ул вакытта продюсерлык безнең өчен ят сүз, аның нәрсә икәнен үзебез дә белми идек. «Союз Продакшн» үзәге «Каеннар арасында» җырына клип төшерергә булды. Әле ул чакта клиплар да яңалык иде. Ә бу үзәк сәнгать мәсьәләсендә алдан күрә белгән икән. Үзәк хуҗасы: «Рәсим, еллар узгач, башка җырлар да башкарырсың, әмма бу җыр гомерлеккә синең белән калачак, бөтен җирдә шуны сораячаклар», – дигән иде. Шулай булып чыкты. Инде җырламыйм дим, тамашачы сорап җырлата. Алдан күрү сәләте шушы була торгандыр.

> Халык җиңел җырларны тиз отып ала. «Каеннар арасында» шундый. Әмма җиңеллеккә омтылам дип, бөтенләй җиңеләергә ярамый. Җырның мәгънәсе булырга тиеш.

Әйе, бу җырга карата сүз күп булды. Мәрхүм Роберт Миңнуллинга: «Роберт абый, сүгәләр бит, нишләтим?» – дип әйткәнем дә булды. «Энем, җырла, җавабын үзем бирермен», – диде. Озак та үтми:

«Син бит шигырь аңламыйсың,
Булсаң да ил агасы.
Каен миңа – сылу бер кыз,
Сиңа – утын агачы», –

дигән дүртьюллык иҗат итте.

Быел үземә – 50, сәхнә иҗатыма 25 ел тула. Бу – җырларыма, репертуарыма анализ ясый торган вакыт җитте дигән сүз. Архивны барлыйм да, берсен аерып, икенчесен читкә куя алмыйм. Әйтик менә Харрас Әюп сүзләренә язылган «Авыл карчыклары» җыры. Анда

«Карашларың моңсу, чәчләрең ак.
Картлык көнең гомер сөргән
җирдән ерак.
Зарыгасың кордашларың хәл-әхвәлен
Авыл якларыннан искән
җилдән сорап», –

дигән юллар бар. Бу җырны сәхнәгә кайтарырга кирәк дип ниятләп куйдым. Ә андый җырлар күп һәм һәрберсе кадерле.

:: Җырның ертыгы буламы?

– Сәхнәгә чыктың икән, нәрсә туры килде шуны җырларга ярамый. Сүз һәм көй берсен-берсе тулыландырган җырның ертыгы юк. Сүзе көенә туры килмәсә, көе булып, сүзе булмаса, анысы ертык була торгандыр. Тамашачыга ияргәндә, билгеле, бу кагыйдәләр белән санлашып тормыйлар.

Кайбер чакта тамашачы кая килгәнен дә оныта бугай, дип уйлый башладым мин хәзер. Урындык аша сикереп чыгу, тамаша вакытында ашау, тәнәфестә нәрсә кылганнарын әйтеп тә тормыйм инде. Болар – ияру, тәрбия функциясен алып бармау җимешләре инде.

:: Сәнгатьтә беренче урында нәрсә: иҗатмы, акчамы?

– Иҗатны табышка әйләндергәндә, шабашникка әйләнәсең. Хәзер ансыз да булмый торгандыр. Яшерен-батырын түгел, сәхнәгә акча эшләү максатыннан чыгучылар да бихисап. Алар бик зур шоу ясарга омтыла. Энергетика, харизма белән алдыралар. Бу миңа туксанынчы еллардагы Чумак, Кашпировскийлар чорын хәтерләтә. Авыру, терелəм дип, телевизор каршына банка белән су куеп, энергетика туплыйм дип утыра иде бит әле, тик ахыр чиктә барыбер хастаханәгә бара иде. Сәхнәдә хәзер шул хәл. Ярсыр-ярсыр да, барыбер чын иҗатка тартылыр әле ул. Һичшиксез, энергетика, харизма кирәк. Җыр белән генә тамашачыны «тотып» торып булмый. Әллә нинди матур җырлар бар. Башкаручының харизмасы булмаса, матур җыр да, җырчы да югала. Минем белән бергә укыган күпме кеше югалды, күпмесе башка һөнәр иясе булып китте.

:: Туксанынчы еллардан соң бик күп җырчы юкка чыкты. Моның сәбәбе нәрсә икән?

– Сәбәп үзеңдәдер. Тукталып калмаска, елга ике җыр булса да яздырырга кирәк. Шул чакта онытылмыйсың.

:: Ә ни өчен беренче урынга иҗатны куйган җырчылар зур конкурсларда, «Үзгәреш җиле» кебек зур фестивальләрдә күренми?

– Конкурсларда, дәүләт чараларында үз вакытында күп катнаштым инде мин. Хәзер исә, миңа калса, зур чараларның әчтәлеген карау, профессионал белән үзешчәнне аралау дигән нәрсә бетте. Бу эш – Мәдәният министрлыгы җаваплылыгында. «Үзгәреш җиле»нә килгәндә, аның кемнәр фестивале икәнен барыбыз да белә. Бу фестивальгә уңышлар телик һәм бер теләкне җиткерик. Алар халык мирасына әйләнгән әсәрләргә кагылмасын иде. Күп җырлар джаз стиленә бөтенләй батмый. Джаз безнең сәнгать түгел бит ул. Әгәр инде бу «... җил» башта конкурс игълан итеп, башта яңа җырлар иҗат итүгә сәбәпче булса, аннан шуны шәп оркестрга башкарттырса, менә шунда, бәлкем, файдасы да булыр иде. Ул кадәр бюджетка әллә нәрсәләр эшләп була.

:: Гаилә иҗатка ничек тәэсир итә?

– Гаилә – минем тылым ул. Тыл булмаса, эш фронты да булмас иде. Ул һәрвакыт – беренче урында. Җырларыма да беренче бәяне гаиләм бирә. Без хатыным Энҗе белән Казан дәүләт педагогия институтында бер курста укыдык. Төркемнәребез төрле булса да, Энҗе сәнгатьтән ерак кеше түгел.

:: Сез гаиләгезне халык күзеннән саклыйсыз бугай. Ә кайбер җырчылар киресенчә, гаилә, «сары» темалар белән дә үзләрен популярлаштыра. Заманның бу сыйфатына ничек карыйсыз?

– Интернет заманында популярлыкны тотуның төрле алымнары бар. Әйе, мин һәрберегезгә ачык кеше дип, гаиләнең һәр көнен социаль челтәрләргә чыгарып була торгандыр. Халык та «сарылык»ны ярата, аңа шәхси мөнәсәбәтләр кызыклы. Минем өчен шәхси ул – шәхси. Аны ха-

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләк?
– Ил-көндә тынычлык булсын. Шул чакта гына күңелгә тынычлык килергә мөмкин.
– Артист булмасагыз, кем булыр идегез?
– Мөгаен, укытучы булыр идем. Шул ук вакытта түземлек җитәр иде микән, дип тә уйлап куям. Бертөрлелектә яши алмыйм. Миңа мохитне алмаштырып торырга кирәк. Шуңа күрә без гаиләбез белән сәяхәт итәргә яратабыз.
– Яраткан җырчыгыз бармы?
– Тыңлап үскән җырчыларым – Илһам абый Шакиров, Әлфия апа Авзалова. Әмма кумир булдырып, аның күчермәсе булырга ярамый. «Татар моңы»нда жюри булганда, Әлфия Авзалова күчермәләрен күп күрергә туры килде. Салаватлар күп булды. Хәзер Тямайлар башланыр, мөгаен *(көлә)*.
– Интернетмы, басма матбугатмы?
– Мәгълүмат белән күбрәк интернеттан танышам. Авылда гомер буе газета алдыралар, кечкенәдән «Ватаным Татарстан»ны беләм. Мин кечкенә чакта ул «Социалистик Татарстан» иде.
– Мөмкинлек булса, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?
– Бернәрсәне дә үзгәртмәс, барыбер шушы юлда булыр идем. Яшьлек белән кайбер әйберләрнең кадере беленмәгән, әмма ул да үзенә күрә сабак булган.

лык белән бүлешергә теләмим. Шәхсине ил-көнгә чыгару шул ук тамашачыга иярүгә кайтып кала.

:: Бу көннәрдә җанисәп нәтиҗәләре буенча кызу бәхәсләр бара. Кемдер татарның 600 меңгә кимүендә үзебез гаепле ди, кемдер гаеплене ерактанрак эзләү яклы. Сез нинди фикердә? Үзегез җанисәптә катнаштыгызмы?

– Гаеп атта да, тәртәдә дә. Бәлкем, үзебез дә актив булмаганбыздыр, бәлки, саннар кайдадыр югалып та калгандыр. Мин гаиләм белән җанисәптә катнаштым. Татар сәнгате вәкиле була торып, ничек катнашмыйча ди инде?! Безнең өйгә килделәр, барыбыз да анкетаны ничек тутыруны карап торып, милләтебезне «татар» дип язганын тикшердек. Шунысы да бар: халыкта милли үзаң дәрәҗәсе түбән. Халык арасында йөргәч, күрәнә: кемнәрдер татарлыгыннан ояла. Араларында русча сөйләшә белмәүчеләр дә бар, әмма үзен татар түгел, ди. Тел бетә, дип кычкырдык, кычкырудан ары уза алмадык. Үзебез үк телне үгисетәбез, сөйләшмибез бит. Мәктәптә татар укытучылары бар, балалар бакчаларында татар тәрбиячеләре бар, татар мохите тудыра алалар бит. Ата-ананы әйтмим дә инде, баласы урысча сораса, урысча җавап бирә. Гаиләдә урысча аралашалар икән, урамда татар мохите юк та юк инде ул.

:: Балаларыгыз татарча беләме соң?

– Әлбәттә. Безнең өйдә аралашу фәкать татарча. Өйдә татарча булмаса, әллә нинди мәктәптә укытсаң да, бала урыслаша инде ул. Без балаларга татарча мохит булдырырга тырыштык. Олы улыбыз татар-төрек лицеенда укыды, кечесе дә шунда.

:: Җырлаудан кала нинди шөгылегез бар?

– Тырышсаң, җыр белән дә тормыш алып барып була. Тик шунысы бар: җыр ул – чыгымлы нәрсә. Аннан соң, тормыш алып барам дип, җырлап кына да яшәп булмый, тавышка арыганлык чыга, чөнки тавыш ярылары арый. Спортчы да бит ярыштан соң ял итә, җырчыга да ял кирәк. Әмма үзеңне гел формада тоту да кирәк. Шуңа күрә берсен-берсе тулыландырсын өчен, нинди дә булса башка бер эш тә эшлисең.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

АСИЯ ЮНЫСОВА

МАДАМ БОВАРИ

Сап-сары өрәңге яфрагы җил белән качышлы уйный. Трамвай юлының шпалы астына качып торгандай итә дә, җил алан-йолан караган арада тагын, җитез мәче баласыдай койрыгын уйнаклатып, икенче бер ышык урын табып сыена. Мәүлия әзелеп төшкән сары яфракның җил белән куышлы уйнавын үзенчә аңлады. Кышка керер алдыннан ышык урын эзли ләбаса. Җылы урын эзли. Югыйсә берәр агач төбендә җирне кочаклап ятса, үзенә дә, җиргә дә уңай булыр иде. Юк шул, башсыз яфрак шпал арасыннан йөгерә.

Бу трамвай дигәне ник озаклады соң әле? Берәр почмакта тагын машиналар тыгылышкандыр инде. Тәмам әрсезләнде алары. Җәяүле юлы дип тормый, трамвай рельслары дип тормый, өстеңә менәргә килгәндәй чабалар. Бәләкәй кешенең хокукы беткән, кадере киткән заман. Талкый торган заман. Әрсез җил өрәңге яфрагын талкыган кебек. Трамвай көтүчеләр дә ишәя бара. Озак көтәсе булыр микәнни?

Мәүлия трамвай юлына аркасын куеп басты. Чын хатын-кызларча, имеш, трамваена да ялынмый! Юлда машиналар конвейердагы кебек агыла гына. Берсенең ишеге ачылып китсен иде дә әллә кайчангы бер танышың: «Нишләп торасың, Мәүлия? Утыр әйдә машинага, чум тизрәк!» – дисен иде. Таныш булмаса да ярый, яхшы кеше генә туры килсен. Туктар, бар – и хыялый! Машиналар арасында ырып-ерып йөргән хәер эстәүче хатыннар бимазалаудан, гарип-гораба бәйләнүдән куркып, тәрәзә пыялаларын да төшермиләр.

Мәүлия үзе руль тотып утырмаслык хатынмы соң?! Машинасы гына юк. Ул машина йөртүче хатын-кызларны санарга керешә. Әнекәем, бер ир-атка бер хатын-кыз туры килә инде әллә? Мәктәбен дә бетереп өлгермәгән чәчбиләренә кадәр руль тоткан. Алар тотар инде, ата-аналары узынлыргач. Ни йөрәгең белән балаңны шушы тимер ташкын арасына кертеп җибәрмәк кирәк! Ничә йөз меңлек машинаңа китереп төртсәләр, хәсрәтеңнән йөрәгең ярылып үләрсең. Юк, Мәүлиягә машина кирәкми, бушка бирсәләр дә кирәкми. Ә менә утырып йөрер иде… Бер сөмсезе шунда җыелган яңгыр суына выжлап килеп керде дә, янәсе, күп мыгырданып торма, Мәүлияне бензинлы түгәрәкләр уйнаган пычрак су белән коендырды. Мәүлия, шакшыдан йөзен яшерергә теләп, кинәт артка, абайламастан, трамвай юлына таба тартылды. Шул мизгелдә колакны тондырып трамвай кыңгыравы шалтырады. Тукталыштагы халык аһ итеп куйды.

– Ай Аллам! Трамвай астына керә бит инде!

Куркудан агарып калган Мәүлия киң ачылып киткән ишектән трамвайга үтте. Трамвай йөртүче кабинасын кыршаулаган тимергә тотынып, сулышы тигезләнгәнне көтте. Аннары, янчыгын чыгарып, җиде сум көмеш санады. Югыйсә юл йөрү билеты бар иде. Сумкасында актарынасы килмәде. Әллә акча түләп билет алуы үзенә күрә сәдака бирүе идеме соң? Исән калган сөенечтән. Кондуктор да бар иде бугай. Мәүлия, нишләптер, акчасын трамвай йөртүчегә сузды. Ир кешенең юлдан күзен алмый гына сузылган кулына кулы тиюдән Мәүлия әллә нишләп китте. Трамвай йөртүченең учы зур, коры, җылы иде. Менә шушы учка йомарланып кереп ятсаң, бик рәхәт булыр иде кебек. Кулындагы билетның озаграк алынмавын сизепме, трамвай хуҗасы каерылып Мәүлиягә карады: «Ә синмени әле бу? Йөрәкне алдың бая».

Мәүлия аклангандай елмаеп куйды. Бүтән хатыннар кебек тиз генә сүз таба алмый ул кирәк чакта. Хыялый булгангадыр инде. Гел уйланып йөргәнгә…

Мәүлиянең чын тормышы – хыялында. Болай ул үзе башкалар кебек – эшкә бара, кайта, кешеләр белән аралаша. Ашарга әзерли. Ашый, юына. Әмма, көнне тәмам итеп, урын-җиргә менеп ятуга ул хыялындагы яшәешенә күченә. Хыялда яшәү шундый рәхәт. Анда синең күзләрең ни күрергә теләсә, шуны күрә, колакларың ни ишетергә тели, шуны ишетә. Хыялда ирешелмәгән теләкләр юк. Чынбарлыктан качунын хыял ишегеннән кереп китү юлын ул бик бәләкәй чакта ук тапты. Һәрвакыт рухи киеренкелектә яшәгән бәләкәй кыз өчен шифалы ачыш булган икән ул. Бәләкәй балаларның уен дөньясы кебек үк шифалы. Сабыйлар да үз-үзләре белән сөйләшеп, япа-ялгыз уйный беләләр бит. Башка балаларның ничектер, Мәүлиянең хыял дөньясында мәхәббәт хөкем сөрә иде. Мәхәббәт дигәннәре башта зурларның кыланышын күреп торып чамаланган сәер дөнья кебек кердe аның күңеленә.

Алты яшьләр булгандыр Мәүлиягә, күршедәге чибәр Зәрәне урладылар. Зурларның аһ-уһ килеп сөйләшкәннәрен кыз колагын торгызып тыңлады. Югары очның Мәхәсим исемле бер егете чибәр Зәрәне тарантаска салган да алып киткән икән. Кыз карышкан, елаган, тешләшкән. «Яратмыйм мин сине, яратмыйм!» – дигән. Шуннан Мәхәсим яшь кәләшен, беренче көннән үк ефәктәй итү өчен, кыйнаган икән, имеш, – ул бит кызны ярата, нигә карыша!

Кичтән күз тирәсе кара янган Зәрә таба сорап керде. Кыяфәтеннән бик оялып кына ишек төбендә таптанды. Мәүлиянең әнисе бик җәлләде аны: «Илаһым, бу бала да минем кебек ише кыйналып гомер итәр микәнни соң?!» Бу төнне Мәүлия озак йокыга китә алмады. Хыялында тарантаска төялеп килгән егетләр аны урларга иттеләр, ул алар белән кышкы юллардан каядыр очты. Әбисенең такмагындагыча иде:

Кызым, кызым – кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше.
Шул йөз кеше арасыннан
Алып китәр бер кеше.

Дилбегәсен урап тоткан егет шул йөзнең берсе икән дә, Мәүлияне бик ярата икән… Мәүлия әле үзе яратуның ни-нәрсә икәнен белми. Әмма үсә-үсә анысын да төшенде. Сыйныфташы Вәдүт гел диңгезче булам дип сөйләнә, абыйсының матрос фуражкасын киеп мәктәпкә дә килә иде. Үзенә төнге хыял өчен иң кулай малай итеп Мәүлия Вәдүтне сайлады. Хәзер ул хыялында айлар буе диңгездә йөзгән Вәдүтне өйдә сабыр гына көтүче инсафлы хатын, алты бала анасы иде. Өстендә дворян хатыннарыныкы кебек озын бәрхет күлмәк… Бу тәти хыял озакка бармады…

Инде сигезенче сыйныфка җиткәннәр иде. Бервакыт, мәктәпнең утын әрдәнәләрен аралаганда, капкадан ялкау гына килеп керүче Тәмизне күреп, кулындагы пычкысын төшереп җибәрде Мәүлия.

– Бик вакытлы килдең, Тәмиз, әйдә Мәүлияне алыштыр, – диде хезмәт укытучысы.

– Юк, юк, арымадым, абый. – Бер башыннан Тәмиз тоткан пычкыга кыз кабаланып килеп ябышты. – Кисәбез әле.

Яңа гына эшкә тотынган Тәмиз белән кулдаш булып пычкы тарту тәмам сулышына капса да, Мәүлия сынатмады. Булдыра ул, шәп ул, көчле ул, чыдам ул! Шул төнне Мәүлия күктәге тулган айны тәүге тапкыр күрде бугай. Элек тә балкыгандыр инде ул. Ләкин бу төнне айның серле нурына түзәрлек түгел иде. Кыз торып утырды, ак пәрдәләрне ачты. Кышкы төнгә көмеш нурлар сибеп балкучы ай тәрәзәдәге бозлы бизәкләр аша Мәүлиягә карый. Белә ул аның өр-яңа серен, белә. Бусы, чыннан да, мәхәббәт иде. Озакка иде. Бәлки гомерлеккәдер дә әле.

Хәзер инде Мәүлия хыял дөньясына төннәрен генә түгел, көндезләрен дә китә. Мәктәп юлында дус кызларын котми. Уйланып барырга комачау итәләр, сөйләштереп. Инештән су ташу җан рәхәте. Инеш ерак. Көянтәңне элсәң дә тар сукмактан җырлый-җырлый барасың. Су ташып йөргән кызга эшлексез дип әйтүче дә юк. Рәхәте белән хезмәте бергә. Кайвакыт эт өйрәтергә чыккан Тәмиз очрап куя. Хәзер инде аның эте дә таный Мәүлияне. Тәмиз мәктәптә кызны күрми. Малайның мәктәптә соңгы елы иде. Мәүлия хыяллана калды, ә ул укып бетерде дә каядыр техникумга китеп барды. Аннан – армиягә. Армиядән Мәүлиягә «дусларча» хат язды. «Синең адресыңны дус малайга бирсәм, үпкәләмәссең бит», – дигән. Мәүлия инде үзе дә шактый тәвәккәл кыз булып үсеп җиткән иде. Дус кызларына да сөйләмәгән серен ачып, җавап хаты юллады: «Тәмиз, дусларыңа бүләк итәр өчен үстердеңмени син мине, суга барган-кайтканымны этең белән бергә саклап…» – дип уенкөлке белән башланган бу хатта башы булган егет аңларлык киная бар иде. «Ялкау бит мин, Мәүлия, хат язарга иренәм. Ә син язсаң, рәхәтләнеп укырмын. Алай да көт әле син мине», – диган сөенечле – әллә ничә мең хыялый төнгә аш булырлык җавап килде.

Тәмиз армиядән өйләнеп кайтты да Себер ягына нефть эшенә китеп барды. Мәүлия Казанга килеп, эшкә урнашты. Әнкәче әти кызын укытырлык акча таба алмады. Мәүлия ирсез генә бала тапты. Хыялында улын Тәмизнеке дип, үз-үзен ышандырды. Малай гаҗәп акыллы булып үсте. Төрек-татар лицейлары андый малайлардан бер дигән кешеләр тәрбияләде. Укуы әйбәт иде. Тиздән, җиз иләктән үткәреп, малайны Төркиягә үк җибәрделәр. Хәзер инде шунда урнашып та калды. Укый да бугай. Башлы малай Мәүлиянең хыял дөньясына ныгытып кереп урнаша алмады. Чөнки хатын, улы яшәгән мохитне начар белгәнлектән, ни рәвешле хыялланырга белмәде.

Мәүлиянең үз дөньясына бикләнеп яшәргә яратуын, әмма олы мәхәббәт хакында хыялланып яшәвен эштә дә беләләр иде. Озак кына Мөслим Магомаевка гыйшык тотып йөргәнен үзе сөйләде. Җырчының җырлары язылган тасмаларны, хәтта элеккеге патефон тәлинкәләрен Мәүлия өчен бергәләп эзләделәр. Хисләреңне яшермәсәң, яхшырак икән. Шуңа күрә хатын хәзер һәр яңа гашыйклыгын эштәге әшнәләре белән уртаклаша.

– Малакаем, синә кияүгә чыгарга кирәк, – диләр аңа.

– Кирәк тә соң, юк бит. Кешедән артканга үзем кызыкмыйм. Буе да, холкы да килгән булсын миңа. Мин җырлаганда кушылып уйнарлык булсын. Каршы дәшмәсен.

– Син бигрәк тагын. Алайса, кинода күргәннәреңне, китаптан укып белгәннәреңне генә ярат ит инде син, Мадам Бовари!

Дәвамы бар >

ОЧЛЫ КҮЗӘТҮЛӘР

- Пәрәмәчләрне ике куллап бик тиз ашасагыз, фитнес-браслет сезне йөгерә дип уйларга мөмкин.
- Яки син тормыштан өйрәнәсең, яки ул сине өйрәтә.
- Генерал белән аерылышасың килә икән – лейтенантка кияүгә чык.
- Бай ирләр карт булмый.
- Искергән даруларны ташлаганда сөенергә дә, көенергә дә белмәссең.
- Безнең илдә вакыт машинасы эшләми. Киләчәк урынына гел үткәнгә алып кайта.
- Кан тапшырганда ул синеке булырга тиеш икән.
- Бет тә бөркеттән югарырак очарга мөмкин, әгәр ул космонавт башында булса.

Әз-мәз мәзәк

Пенсия фондында килеп чыккан сугыштан соң бинага скандинав таяклары белән керүне тыйганнар.

***

– Ни өчен һаман бала тапмыйсыз?
– Песиебездә аллергия.

***

– Бар да яхшы булачак.
– Оптимист икәнсез.
– Юк, чөнки моннан да начаррак инде булырга мөмкин түгел.

***

Ул шундый сәер кеше иде, аның сорауларыннан хәтта «Яндекс» та сискәнеп китте.

***

– Зур түрәнең баласы гади генә мәктәптә укып, техникумны тәмамлап, заводка эшкә урнашуы турында роман язасым килә.
– Фәнни фантастика?

***

Шифаханәдә:
– Исәнмесез! Миңа кан бирергә куштылар. Вампирлар кайсы бүлмәдә утыра?

***

Идеаль машина ясау омтылышы белән дөньякүләм автогигантлар ел саен модельләрен үзгәртеп торалар. «АвтоВАЗ» исә бу идеаль машинаны инде 1977 елда ук уйлап тапты һәм ярты гасыр буе «Нива» чыгара.

***

– Матурым, бу күлмәк мине таза күрсәтә түгелме?
– Юк, йөзең шундый.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: басу, кәлимә, Ройс, имән, әбәк, ләчтит, Нәҗип, чи, Кораб, Лемаев, Әлифба, җилен, Марс, чишмә, Убырлы, Бразилия, какао, Самат, Хөсни, Крок, Су, аты, өн, ранг, Оныт-маган, ант, суер, Лада, Адрит, Сөнәев.

Вертикаль: бахыр, Лилия, ел, Хәсән, чүмеч, Анискин, ике, Барлас, Мәхмүтов, макта, мә, тот, дан, бирнә, ала, болын, Садә, АМО, ыру, ре, Сәйлән, аскет, Ив, кәҗә, узар, Марат, Любимова, ипи, ылак, Фәрит, ля, Сөн, аракы, рун.



Беләсең килсә...

1 Австрия әләмендә нинди төсләр бар?
а) кызыл, яшел;
б) яшел, ак;
в) ак, кызыл.

2 «Шәрафәт» сүзе нәрсәне аңлата?
а) көчле җил, давыл;
б) хөрмәтле, мөхтәрәм;
в) җирәнгеч, күңелгә ятышсыз.

3 Бу шәхес джазны «тазалар музыкасы» дип атаган:
а) Сергей Есенин;
б) Максим Горький;
в) Михаил Булгаков.

4 Дөньядагы иң кыска гимн нибары 18 секунд яңгырый. Ул кайсы илнеке?
а) Уганда;
б) Уругвай;
в) Уэльс.

Җаваплар: 1.в); 2.б); 3.б); 4.а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 212

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+